XIX–XX башында Тау ягындагы иң зур, атаклы мәдрәсә, әлбәттә Акъегет авылы мәдрәсәсе була. Бу мәдрәсәне нигезләүче, соңгы көннәргә кадәр тотучы Шәфигуллиннар, аерым алганда, ике бертуган Шәфигуллинның берсе – Заһидулла Шәфигуллин була. Гомумән, Тау ягындагы күп кенә авылларның мәчет, мәдрәсә хәлләре бу шәхес исеме белән бәйле. Алай гына да түгел, алар исеме, аларның дин һәм мәгарифкә булган хәйриячелек гамәлләре Рәсәйнең ерак Себер якларына кадәр җәелә. Акъегет авылында гына да аның акчасына 3 мәчет һәм мәктәпләр төзелә һәм ремонтлана. Заманында атаклы уку йортының берсе булган – Чүти авылы мәдрәсәсе, мәчете тарихы да Заһидулла Шәфигуллин исеме белән бәйле. Язучы Зариф Бәширинең әтисе Шәрәфетдин заманының алдынгы карашлы мулласы буларак Заһидулла бай белән аралашып яши һәм аның белән яхшы мөнәсәбәттә була. Соңрак улы Зарифул-

ланы да Акъегет авылының җәдитчә укытучы заманча мәдрәсәсенә укырга бирә.

Ул сәүдәгәр, эшмәкәр генә түгел, ә җәдидче буларак бик ихтирамлы һәм танылган кеше була. Аны И. Гаспринский, Г. Баруди, Г. Апанаев кебек атаклы кешеләр бәяләгән. Аның тарафыннан салынган мәктәпләрнең һәммәсендә ысулы җәдидә берлә тәгълим ителә. «Тәрҗеман» мөхәррире Исмәгыйль Гаспринский җәнаблары халыкны ысулы саутиягә өндәгән вакытта иң башлап кабул итүче Заһидулла хаҗи булган» дип яза XX йөз матбугаты. [2; 6–7 б.]. Жандармерия документларында аның хакында «он был Галеевского и Иж-Бобьинского закала» [4; 6 а – 8 б кгз.], дип язылa.

Заһидулла Шәфигуллин 1870 елны үз туган авылы – Акъегеттә мәдрәсә ачып җибәрә. Башлангыч чорында ул башка дини уку йортларыннан берни белән дә аерылмый торган мәдрәсә була. Мәдрәсә үз яшәү дәверендә берничә мәртәбә төзекләндерелә, 1895 елда бина киңәйтелә, чөнки мәдрәсәдә укучылар саны XX йөз башында 300 кешегә җитә. Шәкертләрнең 70 ләбе ерактан килеп укучылар була. Чистай, Буа, Минзәлә өязе авылларыннан килгән балалар һәм яшүсмерләр укый. Хәтта ки, бер шәкертнең Владивостоктан да булуы мәгълүм. Читтән килгән балалар Шәфигуллиннар исәбенә яшәгәннәр дә, алар исәбенә тукланганнар да, белем бирү дә тулысынча алар исәбеннән була. Шәфигуллин бу гамәлләрен бик үк белдерергә теләмәгән, хәтта дәүләт чиновниклары кызыксынганда ул шәкертләрне үз исәбенә тотуын инкяр итә торган була.

Мәдрәсә утары тулы бер комплекстан торган, аның янында укытучылар яши торган ике катлы йорт, шәкертләр юыну өчен мунча, ашау өчен ашханә була, ашханәдә һәрвакыт чәй кайнап торган, шәкертләр теләгән вакытта кереп чәй эчә алганнар. Мәдрәсә комплексының янында алма бакчасы үскән.

1913 ел мәгълүматлары буенча бу мәдрәсәдә 9–18 яшьлек шәкертләр белем алган, бу вакытта аларның саны алдагы елларга караганда 2 тапкыр азрак – бары тик 114 шәкерт укыганлыны күренә. Шәкертләрнең ике тапкыр кимүениндидер сәяси, яисә һич кенә дә мәгариф эшләрендәге кимчелек белән бәйле түгел. Бары тик 1903–1913 еллар арасында Тау ягында берничә мәдрәсә ачыла, шул сәбәпле шәкертләр үзләренә якынрак мәдрәсәләрдә укуларын дәвам иткәннәр. Шәфигуллин химаячелеге нигезендә салынган шундый

мәдрәсә 1913 елның сентябрь аенда Чүти авылында эшли башлый, Тәтеш өязенең Чирмешән авылында да Садыйк Сабитов акчасына мәдрәсә ачыла һәм дә атаклы мәдрәсәләрнең берсе – Буа өязе Норлат авылында эшләп килә.

Заһидулла Шәфигуллин – җәдитче, ул милләт үсешен, аның киләчәген кайгыртучы милли интеллегенция вәкиле. Ул үзе укыйяза белмәсә дә, белем кирәклеген аңлаган, аңлап кына калмыйча, татар халкының киләсе буынарын белемле итүгә бар гомерен багышлаган фидакарь бер зат. Документларда: «Шафигуллин – убежденный сторонник распространения образования в мусульманской среде. При разговорах с должностными лицами Шафигуллин высказывает, что татары необразованны, некультурны и экономически оскудели и что только образование может сделать татар культурными и поднять экономический их уровень» [4; 1–2 кгз.], диелә.

Әлбәттә аның бу гаять киң кырлы эшчәнлеге барлык яктан да ризасызлык тудыра. Беренчедән, тирә-як авылларның муллалары җәдиди укуга шикләнеп, хәтта куркып караулары сәбәпле, әле шуның өстенә урыс класслары ачылу да, традицион карашлы халыкны да, руханиларны да шик-шөһрәгә сала. Икенче яктан, аның мондый кыю, батыр эшчәнлегеннән власть вәкилләре курка. Аларны бу якларда җирле халыкның татарлар кебек кебек үк төп өлешен тәшкил иткән, татарлар белән күп гасырлар бертугандай яшәгән, хәтта ки татарча сөйләшкән чуашларның мөселманлыкка чыгу, татарлашу куркынычы булуы борчый. Эше, гамәле белән көчле Шәфигуллиннар тарафыннан үз мөмкинлекләре, үз капиталы белән моны башкару куркынычы, әлбәттә, зур була.

Тагын бер үзенчәлекле кызык факт: Акъегет мәдрәсәсе уку программасында хәтта урыс классында да рус һәм гомум тарих дигән предмет булмый, ә аның урынына Шәрык тарихы укытылган. Әлбәттә бу гамәле дә бик аңлашыла, беренчедән, ул милләтпәрвәр шәхес, икенчедән ул Шәрыктә сәүдә иткән эшкуар. Бу да властьларны куркыта, шул ук Чебоксар өязе исправнигы болай дип яза: «Я лично убежден, что медресе в д. Акзегиово создано и поддерживается Шафигуллиным в целях религиозно-национального объединения мусульман» [3; 253 а – 255 а кгз.].

1897 елдан башлап Акъегет мәдрәсәсе җәдиди уку программасы белән эшли башлый. Мәдрәсә 1907 елда Икенче Казан укытучы-

лары корылтаеда эшләгән программа буенча, аерым алганда, Апанай мәдрәсәсе уку программасына якын программа белән укыта. Мәдрәсә 5 бүлектән һәм 2 сыйныфтан торган. Беренче класста курсны узу вакыты 3 ел, икенче класста уку курсы 7–8 ел дәвам иткән. Биредә гакаид, тәҗвид, ана теле, арифметика һәм башка предметлар укытылган. Укыту татар телендә алып барылган. Жандармерия документында «он большое внимание обращает на народное образование. В этом старается, чтобы муллы и учителя больше обращали внимание на обучение татарскому языку и светским предметам образования», диелә. [4; 6 а – 8 б кгз.].

Мәдрәсәдәге ысулы саутия методы белән укытуның нәтиҗәлелеген, файдасын, укыту дәрәҗәсен күрсәтү максаты белән дә ел саен ачык имтиханнар оештырылган. Имтиханнарга тирә-як муллалары, Чар һәм күрше өязләрдән мөхтәрәм кешеләр чакырылган. Бу ачык имтиханнарның башка төбәкләрдәге уку йортларының да җәдиди укыту ысулына күчәргә дәлил дә, этәргеч тә була.

XX йөз башында мәдрәсә мөгаллиме вазыйфаларын авыл мулласы Нурулла Ярулла улы үтәгән [5; 1 а кгз.]. Авылның бу беренче мулласы ике башлангыч бүлектә дәресләр алып барган. Дүрт өлкән сыйныфларда дин дәресләрен һәм башка предметларны башлангыч сыйныфларның рус теле укытучысы Фатыйх Сәйфуллин (Фатыйх Сәйфи-Уфалы) укыткан.

1912 елда мәдрәсә каршында рус классы ачыла, үз хисабына рус классы ачуны сорап Заһидулла Шәфигуллин чиновникларга 1908 елда ук мөрәҗәгать итә. Рус телен өйрәнү җирле халык арасында шактый популярлаша, теләүчеләр арткannан-арта бара. Бу класста 84 кеше белем алган өстенә, укырга килергә теләүчеләр тагын да 40 кеше була. Әлбәттә инде мәдрәсә берьюлы шулкадәр кешене сыйдыра алмый, шуңа да рус теле укытучысы Әхмәди Гордеев Шәфигуллин исәбенә рус телен укыту өчен кичке курслар ачарга рөхсәт бирүне үтенә. Әлбәттә инде, ризалык бирелми. Чиновник татарларга рус теле укыту белән аларның дөньяга чыгу, аралашу даирәсенең киңәюеннән шүрли.

З. Шәфигуллин авылда кызлар укыту эшенә дә нигез сала. Иң беренче итеп кызлар мәктәбен үз өендә, үз исәбенә ачып җибәрә. 1913 елга кадәр кияүгә чыгып, авылдан киткәнчегә кадәр кызларны

укыту эшенең башында озак еллар буе үз кызы Әсма тора [3; 253 а – 255 а кгз.].

Кызлар мәктәбенең дә үз бинасы барлыкка килә. Мәктәп югары очта тау башына салынган ике бер катлы бинадан торган. 1913 елга караган волость идарәсе документлары буенча күрсәтелгән вакытка монда 130 кыз белем алган, ә Шәфигуллиннар мәгълүматы буенча бу вакытта укучы кызларның саны күбрәк – 140 кыз була. Кызлар мәктәбендә дә рус классы эшләгән: 1912 едан башлап монда рус теленнән М. Салихова, ә татар классларында 1913 елдан башлап М. Камалова белем биргән [5; 6 а – 8 б кгз.]. Укытучылар өчен дә, укучылар өчен дә менә дигән шартлар тудырылган була. Ике укытучы укытучылар өчен махсус төзелгән бинада яшәгәннәр. Рус классларында уку срогы 4 ел булса, татар классларында уку срогының кысалары билгеләнмәгән була.

Гомер буе үз акчасына мәктәп, мәдрәсәне яшәткән Заһидулла Шәфигуллинның картлык көннәрендә бу уку йортларын тоту авырлаша башлый. 1910 елда 71 яшендә булган Заһидулла Шәрифуллин эшләренә ярдәм итүне үтенеп власть органнарына мөрәҗәгать итә [5; 6 а – 8 б кгз.]. Шәфигуллинның властьлар белән мөнәсәбәтләре нинди генә катлаучы булуга карамастан, аның мәгариф өлкәсендә гомерлек күрсәткән хезмәте алар тарафыннан да бәяләнгән. Хәтта аның мөрәҗәгатен канәгатьләндерелеп кенә калмыйча, Земство собраниесе исеменнән күпьеллык фидакярь хезмәте өчен бүләкләүгә тәкъдим ителә. Хөкүмәт тарафыннан да финансланганга, бу мәдрәсә соңгы елларда инде «Русско-татарская школа» буларак эшли. Аның бар эшләгән хезмәте 1917 елгы инкыйлаб килгәч, чәлпәрәмә килә. Шул кадәр хезмәт куйган 79 яшьлек хаҗи бабайны авылдан китәргә мәҗбүр итәләр, бәхетенә каршы ул шул елны үлә һәм үз туган авылы зиратында җирләнә. Ул төзеткән мәдрәсә бинасы 1929 елга яраксыз хәлгә килә һәм ябыла. Аның күргәзмә материаллары, географик карталар Норлат мәктәбенә алына. Мәгариф үзәге булган авылда укытырга бина булмау сәбәпле, бары тик дүртъеллык мәктәп кенә кала [6; 164 б.].

Бу уку йорты татар мәгарифе тарихындагы уку йортларының бары тик берсе, андыйлар бик күп була, һәрберенең тарихын барлау, аларның дәрәҗәсен күрсәтү татар мәгарифенең югарылын бәяләү булыр иде. Татарлардагы һәрбер уку йорты эше, һәр мулла-

ның ачкан мәктәбе тарих өчен әһәмиятле һәм кадерле. Хөкүмәттән бер тиен алмыйча, шуның өстенә әле төрле тикшерү, яла ягуларга каршы торып эшләнгән эш икәнен истән чыгарырга ярамый. Шул ук мәктәпләр, мәдрәсәләр татар җәмгыятенең киләчәген хәл итә торган бер үзәк була, беренчедән, алар мәгариф үзәге, икенчедән, иҗтимагый үзәк тә. Шул ук Акъегет авылы мәдрәсәсе XX йөз башындагы хәлиткеч чорда заманының алдынгы, прогрессив карашлы зыялыларын туплый, хәтта пропаганда максатында шул мәдрәсә шәкертләре халык арасында эшли. Шул исәптән, без белгән язучы Зариф Бәшировкә дә шул эш йөкләнә.

Акъегет мәдрәсәсенең кыскача гына тарихы нигезендә XIX йөз – XX йөз башында татар мәгарифенең югарылыгын каршы якта торучы жандармерия документларындагы фраза белән күрсәтсәк, аның югарылыгы, шул чорда мәгариф үсешенә, алгарышына гомерен багышлаган шәхесләрнең эшен бәяләүдә артыгын әйтеп булмас иде. Жандармерия документларында З. Шәфигуллин турында «в дни пресловутой свободы он мечтал иметь в своей деревне нечто вроде татарского университета» [4; 6 а – 8 б кгз.], диелә. Ягъни авыл җирендә, авыл мәдрәсәләрендә татарның инде университеты тудырылган була.

## ӘДӘБИЯТ


1. Медресе Казанской губернии второй трети XIX – начала XX в.: сборник документов и материалов / Отв. сост. Л.В. Горохова; сост. Р.А. Гимазова, О.В. Федотова, Н.А. Шарангина. – Казань: Главное архивное управление при Кабинете Министров Республики Татарстан, 2012. – 288 с.
2. Русия сәүдәсе, 1913. Б. 6–7.
3. Татарстан Республикасының Дәүләт архивы (ТР ДА). 1 ф. 4 тасв. 5482 эш. 253 а – 255 а кгз.
4. ТР ДА. 1 ф. 4 тасв. 6183 эш.
5. ТР ДА. 160 ф. 1 тасв. 1834 эш. 1 а кгз.
6. Тимершин И. Акъегет авылы тарихы сәхифәләре. – Казан, 2001.

# РОЛЬ СЕЛЬСКИХ МЕДРЕСЕ В РАЗВИТИИ ТАТАРСКОГО ПРОСВЕЩЕНИЯ

***Салахова Эльмира Кадимовна,***
*кандидат исторических наук,*
*Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, г. Казань,*
*ilsalah@mail.ru*

Статья посвящена изучению истории татарских учебных заведений – медресе, расположенных в сельской местности. Цель автора – показать значимость и роль сельских медресе в развитии татарского просвещения. На примере одного из учебных заведений – Акзегитовского медресе показываются организация обучения детей в конце XIX – начале XX вв., уровень подготовки его выпускников. Также подчеркивается роль отдельных личностей в создании татарских учебных заведений высшего уровня, которые нисколько не уступали университетам того времени.

***Ключевые слова:*** татарское просвещение, джадидизм, Шафигуллин, школьное образование, история татарского народа, медресе.

# THE ROLE OF RURAL MADRASSAS IN DEVELOPMENT OF TATAR EDUCATION

***Salakhova Elmira,***
*Candidate of Historical sciences,*
*Sh.Marjani Institute of History*
*of the Tatarstan Academy of Sciences, Kazan,*
*ilsalah@mail.ru*

The article is dedicated to the study of the history of Tatar educational institutions (madrassas) located in rural areas. The aim of the author is to show the importance and role of rural madrassas in the development of Tatar education. On the example of Akzigit madrassah author shows the organization of education of children in the late $19^{th}$ – early $20^{th}$ centuries, the level of training of its graduates. It also emphasizes the role of individuals in the creation of Tatar higher education institutions, which can be compared with the universities of the time.

***Keywords:*** Tatar education, jadidism, Shafigullin, school education, history of the Tatar people, madrassa.

УДК 37

# ДӨНЬЯВИ БЕЛЕМ АРТЫННАН (ТАТАР СТУДЕНТЛАРЫ ЧИТ ИЛ УКУ ЙОРТЛАРЫНДА)

***Мортазина Ләлә Рәис кызы,***
*педагогика фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Ш.Мәрҗәни исем. Тарих институты, Казан,*
*lyalyatur@mail.ru*

Мәкаләдә XX гасыр башында татар яшьләре арасында күренә башлаган чит ил уку йортларында дөньяви белем алу күренеше тасвирлана. Аерым шәхесләр, аларның кайбер хезмәтләре атала, татар җәмгыятендә дөньяви белем алуга мөнәсәбәт яктыртыла.

***Төп төшенчәләр:*** дөньяви белем, татар студентлары, чит ил уку йортлары, Европа, Америка, Япония, милләт мәнфәгатьләре.

XIX гасыр ахырында Россиядә барган барган хәлиткеч үзгәрешләр, яңа капиталистик мөнәсәбәтләр формалашу, индустриаль үсеш, яңа шартлар татар җәмгыятендә, аерым алганда татар мәгарифе үсешендә дә чагылыш таба – дөньяви белемгә булган ихтыяҗ бермә-бер арта. Татарларның дөньяви белемгә нигезләнгән мәгариф системасы булмау аларны рус уку йортларына этәрә. Тик рус гимназияләре һәм югары уку йортларына юл татарлар өчен нигездә ябык булу проблеманы хәл итәргә мөмкинлек бирми. Шул сәбәпле татар яшьләре чит илләрдә, аерым алганда, Европа, Америка һәм Япония уку йортларында, уку мөмкинлеген күз алдында тоталар. Әмма татар җәмгыятендә рус һәм чит ил уку йортларына барып белем алу мәсьәләсе берьяклы гына каралмый. Күп очракта читтә белем алган татар яшьләренең чын милли рухларын саклап кала алулары, милләт мәнфәгатьләрен кайгырта алачаклары, читтә алган белемнең Россия шартларына туры килүе шик астына куела. Әлбәттә, милли булмаган уку йортларында, шул исәптән рус гимназия һәм университетларында, белем алу татарларның үз-үзләрен тотышларында, киемнәрендә, сөйләшүләрендә һәм кайбер әхлакый сыйфатларында чагылыш тапкан. Татар җәмәгатьчелегенең аерым бер өлешендә бу күренеш миллилекнең, милли рухның юкка чыгуына сәбәп булырга мөмкин дигән фикер тууга сәбәпче булган.

«Йолдыз» газетасының 1906 елгы 1 октябрь санында дөнья күргән «Вак-төяк тырышу» дигән мәкаләдә, мәсәлән, автор европача киенү («пальто-мальто кияләр»), үз-үзеңне тотудагы үзгәрешләргә эче пошуын белдерә һәм аларга каршы көрәшергә, бу «начар гадәтләрне бетерергә тырышырга кирәк»леген белдерә. Төркиядә бер төркем картлар бу гадәт белән көрәшеп карадылар, тик үзләре дә әлеге шаукымга бирелделәр, нәтиҗәдә «а-ля-франка» киенә башладылар, дип яза. Рус телен өйрәнү, рус уку йортларына укырга керү дә, автор фикеренчә, миллилеккә каршы килә, ләкин «Дәүләт думасына, Земский собраниеләргә мөселманнар да член булып сайланган» бер чорда моны бөтенләй тыю да мөмкин түгел. «Бу урыннарга күбрәк укыган кешеләр сайланмак. Чөнки бу урыннарда членнарның канун вә мәгарифтән мәгълүматы никадәр артык булса да, мөселманнарга шулкадәр файда китерәчәк», – дип тәмамлый ул мәкаләсен, үзе үк күтәргән проблемага беркадәр җавап биреп [1].

Ләкин шул ук вакытта татар яшьләренең рус һәм башка чит телләрне белүләре, чит ил уку йортларында белем алу ихтыяҗы, кайбер очракта мәҗбүрилеге булу әле XIX гасыр ахырларында ук дәлилләнгән булуын әйтеп китү кирәк. Мәсәлән, Ш.Мәрҗани Ватан теле булган рус телен өйрәнү бик мәслихәт, чөнки ул дәүләтнең законнарын белү өчен бик кирәк, дип санаган. Тик рус уку йортларына укырга кергәнче татар кешесе башлангыч белемне үз ана телендә алырга, милли тел вә язуыннан хәбәрдар булырга, дини гыйлемнәргә ия булырга тиеш дигән фикерне әйткән. Фикерен нигезләп, ул «Дөньядагы төрле телләрне белүгә, мәгърифәт барлыкка килүгә ислам дине каршы түгел. Фәкать исламны яхшы аңларга, инануны дөресләргә кирәк. Шулай иткәндә, русча уку зыян итмәс», – дигән [2, б. 628]. «Үз милләтемезнең яшәргә тырышуы, үз эшене үзе эшли алуы, хәят миданендә изелеп калмавы өчен Аурупаның голүм вә мәгарифенә, һөнәр вә сәнәгыятенә зур ихтыяҗымыз бар. Аурупаның мәктәпләрендә укымак безнең өчен файдалы. Һөнәр вә мәгариф кайда булса, шунда барып тәхсыйль итәргә кирәк. Гыйлем берлә мәгарифнең хас ватаннары, хас лисаннары юк» [2, б. 628]. Монысы да Ш.Мәрҗани сүзләре.

Чит илләрдә, чит телләрдә белем алуның татарлар һәм гомумән татар милләте өчен бары тик файда гына китерәчәклеген анда укучы татар студентлары үзләре дә таныган. Чөнки алар барысы да киләчәктә үзләрен татар милләтенә хезмәткә, милли тәрәккыятьне

үстерүгә багышлауны максат иткәннәр. Сан-Франциско университетында укучы Хәбибулла Байбулатов, мәсәлән, 1911 елда «Вакыт» газетасында: «максудым – һәр ни кадәр җәфа чигеп булса да, бер һөнәр үгрәнгәннең соңында үз ватандаш вә милләттәшләремә хезмәт итмәк вә файда китермәктер», – дип язып чыга [3]. Америкада белем алучы Фуад Әнвәров татар яшьләре дә Вальпараисо университеты кебек танылган уку йортларында укырга тиеш дип саный: «Без дә башка милләт яшьләре кебек барлыгыбызны күрсәтик, татарның нәрсә икәнлегеннән хәбәре булмаган америкалыларга аның Шәрыктан туып килә торган кояш шикелле төрле вә өметле бер милләт булганын белдерик. Үземездән гали булган башка милләтләр арасында таралыйк. Алардан дәрес алып бераз дөнья күрик. Бездә дә тырыш, гыйлем-мәгърифәт гыйшкы булган, шуның илә бәрабәр зиһен вә фикерләре башка милләт балаларыннан бер дә ким булмаган татар балалары аз түгел. Шушындый җирләрдә укысалар, боларның да башка милләт балалары шикелле үк кеше булачаклары, болар арасында да зур кешеләр, гыйлем-мәгърифәт әһелләре, һөнәр вә сәнәгать әрбабы җитешәчәге кояш кебек заһирдыр (ачык – *Л.М.*)», – ди яза [4, б. 56].

Татарлар арасында чит илләрдә белем эстәү югары яки урта махсус белем алу белән генә түгел, бәлки гомумән сәнәгати, техник күнекмәләрне киңәйтү максатыннан да булуын ассызыклап үтү дә мөһимдер. Чөнки XIX гасыр ахырларында татарлар яшәгән төбәкләрдә сәнәгать үсешенең төрле яңа юнәлешләре барлыкка килү күзәтелә, алар өчен белемле белгечләр әзерләү хаҗәте туа. Җитештерүнең кайбер өлкәләрендә хәтта рус уку йортларын һәм рус предприятиеләрен читләтеп, турыдан-туры сәнәгатьнең әлеге төре аеруча зур үсеш алган Европа илләренә бару күренеше күзәтелә. Мәсәлән, XIX гасыр ахырында татар авылларында, аерым алганда Чистай һәм Казан өязенең кайбер авылларында шырпы фабрикалары ачылу, ләкин аларның җитештерүчәнлек ягыннан бик түбән дәрәҗәдә булуы әлеге төр производство нык үсеш алган чит илләрнең алдынгы тәҗрибәсен өйрәнү иҗтыяҗын барлыкка китерә, димәк, шул илләрдә белем алуга юл ача. Казан өязенең Юртыш авылыннан шырпы фабрикасы хуҗасы Шакир Хәмитов, 90 нчы еллар башында үзенең улын шырпы эшен тирәнтен өйрәнү өчен Австриягә җибәрә. Аннан ул Швециягә, соңыннан Германиягә юл ала, берничә ел дәвамында үз эше буенча алдынгы технологияләрне һәм

чит телләр өйрәнеп, яңа җиһазлар алып, туган авылына кайта һәм шырпы җитештерү эшен яңа юлга салып, заманча шартларда һәм югары җитештерүчәнлек белән дәвам итүгә ирешә, шактый зур фабрикага әверелә. Моның өстенә, югары технологияләрне өйрәнү шырпы җитештерүдә кеше сәламәтлеге өчен зарарсыз булган фосфорсыз методны куллану мөмкинлеген тудырган [5].

Татар яшьләренең күбесе чит ил уку йортларына мәдрәсәләрдә дини һәм милли белем алып, укуларын рус гимназияләрендә дәвам итеп, нигездә Төркия уку йортлары аша килгәннәр. XIX гасыр ахырларында Европа уку йортларында белем алучы татар студентларының саны чагыштырмача күп булмаса да, XX гасыр башында алар инде шактый булган. 1914 елга Европада 15000нән артык россияле белем алган, алар арасында татарлар да җитәрлек булган [6]. Бу чорда Америка уку йортларында да, аерым алганда, Айова, Сан-Франциско, Вальпараисо университетларында татарлар белем алган. Бер татар студенты – Мөнир Ибраһимов – Япониядәге Васэда университетында укыган.

Чит илләрдә, аеруча Европада укучы татар студентларының күпчелеге хәлле гаиләләрдән чыккан. Атаклы алтын эшкәртү сәнәгатьчесе һәм химаяче Мөхәммәтсадыйк Рәмиев балаларга европача белем бирергә кирәк, тик ул татарга юнәлдерелгән һәм милләт мәнфәгатьләрен кайгыртырга тиеш дип санаган. Аның уллары Шакир һәм Закир Рәмиевләр Төркия һәм Европада, оныклары Льеж, Фрайбург университетларында, тау эшләре институтларында укыган. Алар белән бер үк чорда Оренбург бае Сәйфелмөлековның уллары да укыган. Ләкин бары тик бай балалары гына чит ил университетларында белем алган дигән фикер бик үк дөреслеккә туры килми. Бигрәк тә Америкада укучылар арасында урта хәлле гаиләләрдән чыккан, ләкин сәләтле һәм белем алуга омтылышы булган татарлар булган. Америкага барып җитү өчен юлга, беренче ел укуга акча туплаган хәлдә, алар алга таба үзләре эшләп укый алганнар. Юлга акча туплауда татар эшмәкәрләре, җәмәгатьчелек, аерым шәхесләр ярдәм иткән. Шулай ук татар студентларына ярдәм итү җәмгыятьләре дә үз өлешләрен керткән. Татар газеталарында 1911–1914 елларда дөнья күргән мәкаләләрдә (аларның авторлары татар студентлары үзләре) ярдәм иткән аерым шәхесләрнең исем-фамилияләре атала, аларга рәхмәт белдерелә.

Чит илләрдә белем алган татарларның үзләренә килгәндә, алар арасында иң мәшһүрләре – Садри Максуди һәм Сара Шакуловадыр, мөгаен. Садри Максудига Европада белем алырга заманында остазы И.Гаспралы киңәш биргән була: «Әгәр белем алырга телисең икән, син, һичшиксез, Франциягә бар. Париж университеты – дөньядагы иң алдынгы уку йорты. Анда укысаң, биредә дә, үз илеңдә дә шөһрәт казанырсың, абруйга ия булырсың» [7]. Шул рәвешле, С.Максуди, остазының сүзен тыңлап, 1901 елда Сорбонна университетының юридик факультетына укырга керә. С.Шакулова шулай ук Сорбаннада белем ала, татар хатын-кызларыннан беренче буларак, 1913 елда университетның төгәл фәннәр факультетын тәмамлый.

Моннан тыш, Гаяз Максудов, Йосыф Акчура кебек атаклы татарларны, шулай ук киң җәмәгатьчелеккә бик үк таныш булмаган башка шәхесләрне атарга мөмкин. Алар арасында Американың Индиана штатында урнашкан Вальпараисо университетында авыл хуҗалыгы инженеры белгечлеген үзләштергән сибирияле Фуад Әнвәров һәм ташентлы Галимҗан Сәйфелмөлеков бар. Алар турында Вальпараисо университеты архивыннан да материаллар табылды [8]. Әлеге татар студентларына өстәп, шушы чорда Сан-Франциско университетында укыган Хәбибулла Байбулатовны, Айова штаты университетында белем алган Закир Габдуллинны, Льежда белем алучылардан Бәдретдин Сәйфелмөлековны, Гариф һәм Мидхат Рәмиевләрне, Галимҗан Идрисине, Германиянең атаклы Фрайбург тау институтында белем алган Искәндәр Рәмиевне, Васэда университетында белем эстәгән Әхмәдмөнир Ибраһимовны һ.б.ны атарга була. Әлеге шәхесләр турында XX гасыр башы вакытлы матбугатыннан, архивлардан шактый мәгълүмат тупланды, аларның төрле илләр, халыклар, гореф-гадәтләр, анда яшәү һәм уку шартлары, мәгариф системасының үзенчәлекләре турындагы фикерләрен туплаган мәкаләләре өйрәнелде.

Чит илләрдә укыган татар студентлары үзара аралашып яшәргә тырышканнар. Алар уртак кичәләр, лекцияләр, съезлар оештырганнар, фондлар, ярдәм җәмгыятьләре булдырганнар, бергәләп күңел ачканнар. Шундый җыелышларның берсе – россияле студентларның съезды 1914 елда Берндa узган, анда татар студентлары да катнашкан [9]. Льежда һәм башка Европа университетларында, аерым алганда Германиядә, укучы татар студентлары Мидхәт, Га-

риф, Искәндәр Рәмиевләр, Бәдретдин Сәйфелмөлеков, Галимҗан Идрисиләр бергәләп «Мөселман студентлары җәмгыяте»н оештырганнар. Моннан тыш, алар күрше илләрдән җыелып, якшәмбе көннәрендә бергәләп ял итәргә яратканнар, төрле Европа шәһәрләре буйлап экскурсияләр оештырганнар, анда яшәүче халыкларның традицияләрен, тарихларын өйрәнгәннәр [10, б. 304].

1914 елда Америкада чит илләрдән килеп укучы студентларның җәмгыяте оеша. Шул ук елның маенда Де-Мойн шәһәрендә (Айова штаты) чит ил студентларының җыелышы була, анда татар студентлары исеменнән Закир Габдуллин чыгыш ясый [11]. Бөтен илләрнең студентлары катнашында махсус съезд, конференцияләр дә оештырыла, шундый чараларның берсен «Космополитан» исеме астында 1915 елда Сан-Францискода уздырырга карар кылына, анда татарлар да катнашырга тиеш була [12, б. 34].

Татарлар Европа һәм Америка уку йортларында хокук белеме, авыл хуҗалыгы, медицина, электротехника, төгәл фәннәр, телләр, философия, тау эшләре белгечлекләре буенча белем алганнар. Күпчелеге Ватаннарына кайтып, алган белемнәрен милләтебезгә хезмәткә багышлый алганнар, кайберләре, кызганыч, гомерләрен чит илләрдә уздырырга дучар булалар. Мәсәлән, бертуган Искәндәр һәм Гариф Рәмиевләр Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, 1914 елның августында соңгы поезд белән Россиягә кайтырга карар кылалар. Тик Искәндәр поездга утыра ала, ә Гариф өлгерә алмый кала, туганы Искәндәрнең һәм үзенең чемоданнары белән перронда басып кала. Россиягә кайткач Искәндәр әтисе эшен дәвам итә, Баймак бакыр кою заводында хезмәт итә. Гариф, кайбер башка татар студентлары кебек үк, Ватаныннан мәңгелеккә аерылып, бүленеп кала. Чит җирләрдә яшәсәләр дә, татарлар, үзләре куйган максатларына тугъры калып, милләткә ярдәм итү, татар мәнфәгатьләрен кайгырту юлларын эзләгәннәр. Мәсәлән, Бәдретдин Сәйфелмөлеков, Германиядә медицина университетын тәмамлаганнан соң, татарларның тешләре турында диссертация язган, анда ул медицинага караган проблемалар белән беррәттән, татар халкының йолалары, этнографиясе турында да кызыклы гына мәгълүматлар биргән. Моннан тыш, ул Берлин университетында татар теле укыткан, татар фольклорын җыйган. Б.Сәйфелмөлеков Г.Идриси белән берлектә Германиядә татар әсирләре өчен «Татар иле» газетасын чыгарганнар һ.б.

XX гасыр башында татар мәгарифе үсешенең бик кызыклы, үзенчәлекле юнәлеше булган чит илләрдә белем алу мәсьәләсе әлегә бик аз өйрәнелгән. Әлеге тикшеренүләр күп очракта вакытлы татар матбугаты һәм үз архивларыбызда сакланган мәгълүматларга нигезләнә. Гомумтатар педагогик фикер үсешенең аерылгысыз бер өлеше булган әлеге мәсьәләне алга таба чит ил архивларында саклануы материаллар аша өйрәнү аның башка үзенчәлекле һәм кызыклы аспектларын ачыкларга мөмкинлек бирәчәк.

ӘДӘБИЯТ


1. Тимербай. Вак-төяк тырышу // Йолдыз. – 1906. – № 4 (1 октябрь).
2. Мәрҗани: Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вилаятенә йөз ел булу (1233–1333) мөнәсәбәте илә нәшер ителде. – Казан: «Мәгариф» матб., 1915. – Б. 639.
3. Байбулатов Х. Америкадан мәктүб // Вакыт. – 1911. – 11 сентябрь.
4. Әнвәров Ф. Вальпараисо университеты (Америкада) // Шура. – 1915. – № 2. – Б. 56.
5. Хәсән Манашев. Мөселманнарда һөнәр вә сәнәгать // Вакыт. – 1914. – 28 гыйнвар (№ 1401).
6. Вакыт. – 1914. – 14 февраль.
7. Бекирова Г. Садри Максуди: «Мой духовный отец – Исмаил Гаспралы». URL: https://ru.krymr.com/a/28380169.html (дата обращения 13.11.2018).
8. Мортазина Л.Р. «Һөнәр вә мәгариф кайда булса, шунда барып тәхсыйль итәргә кирәк» (Ике татар студенты Америкада) // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2018. – №1. – Б. 164–178.
9. Бернда русияле студентлар съезды // Вакыт. – 1914. – 17 май.
10. Муртазина Л. Садри Максуди с татарскими студентами в Льеже: история одной фотографии // Историческая этнология. – 2018. – №2. – С. 302–311.
11. Америкада татар студентлары // Вакыт. – 1914. – 9 май.
12. Мортазина Л. «Шул татарны күрәсе иде, нинди кеше икән?» // Мирас. – 2018. – №7. – Б. 31–37.

# «ЗА ЕВРОПЕЙСКИМ ОБРАЗОВАНИЕМ, НО С АКЦЕНТОМ НА ТАТАРСКОЕ»: ТАТАРСКИЕ СТУДЕНТЫ В ЗАРУБЕЖНЫХ УЧЕБНЫХ ЗАВЕДЕНИЯХ

***Муртазина Ляля Раисовна,***
*кандидат педагогических наук,*
*Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, г. Казань,*
*lyalyamur@mail.ru*

В статье рассматривается проблема получения татарской молодежью образования в зарубежных учебных заведениях Европы, Америки и Японии в начале XX века. Указываются некоторые личности, также их труды. Освещается вопрос об отношении к получению светского образования в татарском обществе начала XX века.

***Ключевые слова:*** светское образование, зарубежные учебные заведения, татарские студенты в Европе, Америке, Японии.

# FOR EUROPEAN EDUCATION WITH THE TATAR PECULIARITIES (TATAR STUDENTS IN FOREIGN EDUCATIONAL INSTITUTIONS)

***Murtazina Lyalya,***
*Candidate of Pedagogical sciences,*
*Sh.Marjani Institute of History*
*of the Tatarstan Academy of Sciences, Kazan,*
*lyalyamur@mail.ru*

The article deals with the problem of obtaining of higher education by Tatar youth in foreign educational institutions in Europe, America and Japan in the early 20th century. Some personalities are indicated, as well as their works. The attitude to secular education in Tatar society at the beginning of the 20th century is analised.

***Keywords:*** secular education, higher education, foreign educational institutions, Tatar students in Europe, America, Japan.

УДК 94 (470)

# ПРЕОБРАЗОВАНИЕ ШКОЛЫ Г.ЯУШЕВОЙ В ДАРЕЛЬМУГАЛЛИМАТ

***Зиннатуллина Алсу Анваровна,***
*Институт истории им.Ш.Марджани АН РТ, г. Казань,*
*jamash.00@mail.ru*

В статье рассматриваются основные способы решения вопроса подготовки педагогических кадров для новометодных мусульманских школ. Раскрываются процессы реорганизации школы Гайнии Яушевой в средне-профессиональное учебное заведение, освещаются основные правила поступления в училище, уделяется внимание педагогическому составу учебного заведения.

***Ключевые слова:*** Гайния Яушева, татарская интеллигенция, новометодные школы, школьные правила и устав, педагогическое училище, педагогическое образование.

В традиционной системе мусульманского образования обучением девочек занималась абыстай, которая учила в основном только чтению, и с помощью прочитанных книг давала главным образом религиозно-нравственное воспитание и готовила послушных носительниц вековых традиций и нравов. С конца XIX столетия мусульманская образовательная система начинает интенсивно реформироваться: начинают создаваться новометодные или джадидистские школы, где обучение грамоте опиралось на новый звуковой метод, где вместе с религиозным образованием вводились светские предметы, также происходили коренные изменения всего учебного процесса. Одним из новшеств, внедряемых в новометодные школы, было и появление педагога-женщины, учительницы, от которой требовались определенные педагогические знания. Однако в начале XX века не было ни одного специального педагогического учебного заведения, где могли бы готовиться учительницы для новометодных женских школ.

На всеобщее обсуждение вопрос о необходимости открытия мусульманской женской учительской школы первый раз выдвигался в 1911 г., когда предстоящий двадцатипятилетний юбилей пребывания М. Султанова на посту муфтия ОМДС было предложено

ознаменовать каким-либо полезным для нации делом [7, с. 242–242]. Следующая попытка была сделана в 1913 г., по случаю празднования 300-летнего юбилея царствования династии Романовых. В обоих случаях были созданы комиссии для изучения вопроса и подготовки документации. Однако эти попытки не нашли поддержку со стороны вышестоящих лиц и вопрос остался не решенным.

Особенно после вышеперечисленных событий, на страницах периодической печати начинают появляться статьи, критикующие бездеятельность членов комиссии, а представительницы татарской общественности выступают со своими предложениями по решению проблемы. Например: редактор газеты «Сибирия» Ф.-Ф. Наврузова в рубрике «Из женского мира» газеты «Баянел-Хак» жалуется на бесправное положение учительницы и отмечает, что ждет удовлетворительного решения мусульманского женского учительского вопроса не от мужчин-мусульман, а от самих мусульманок-учительниц [3].

Надо сказать, что ее голос был услышан, и педагогическим учебным заведением, предназначенным для женщин, стала учительская школа, открытая в г. Троицке в 1915 г. Эту школу назвали дарельмугаллимат, т.е. женская школа для подготовки учителей.

После закрытия в 1912 г. Иж-бобинской женской школы М. Буби по приглашению Г. Ахмерова осенью того же года переезжает в г. Троицк и начинает обучать девочек. Одновременно она ведет разъяснительную работу среди жителей Троицка о необходимости обучения девочек и агитирует известных троицких купцов и меценатов Яушевых открыть женское медресе или женскую учительскую семинарию. Необходимость создания женской учительской семинарии она объясняет тем, что для полноценного обучения девочек необходимо, чтобы в каждом классе была своя учительница, а не одна для всей школы [4, с. 163–164].

Через некоторое время вдова ташкентского купца М.А. Яушева – Гайния, при поддержке сына Л. Яушева, решается учредить в г. Троицке неофициальную четырехклассную женскую школу «Медресе Гайния» [6].

7 августа 1914 года проходит торжественное открытие школы. Г. Яушева становится управляющей, а М. Буби – заведующей учебной частью.

1 июля 1914 года вступают в силу «Правила о частных учебных заведениях, классах и курсах Министерства народного просвещения, не пользующихся правами правительственных учебных заведений» [5, с. 567–574], согласно которым, при учреждении частными лицами учебного заведения, упрощались некоторые организационные моменты и предоставлялась определенная свобода в выборе языка преподавания. По «Правилам…» русский язык, история и география России в обязательном порядке должны были преподаваться на русском языке, а остальные предметы на родном языке того народа, для кого это учебное заведение было открыто, т.е. «исключительно для детей, которые говорят только на этом языке».

Опираясь на эти правила, Г. Яушева начинает процесс преобразования четырехклассной школы в дарельмугаллимат. «Интерес женщин-татарок к получению образования в последние годы растет с невиданной быстротой», – отмечает она в предисловии программы дарельмугаллимат. «На сегодняшний день в школах вместе с ученицей начальных классов можно увидеть и девушек, и беременных дам, и пожилых женщин. Этот чрезмерный рост количества учащихся привел к тому, что во многих местах не хватает квалифицированных учительниц, да и таких учебных заведений для татарских девушек можно сказать, что вовсе нет. По закону 1 июля 1914 года, чтобы частично сократить спрос к учительницам, мы начали работу по созданию частной школы по подготовке педагогических кадров» [8, с. 2], – пишет она, обосновывая свои действия.

15 мая 1915 г. Г. Яушева получает разрешение на открытие дарельмугаллимат, а 18 мая того же года Попечителем Оренбургского учебного округа утверждается устав данного учебного заведения [1, с. 408]. По утвержденным документам это – «среднее частное женское мусульманское учебное заведение, в составе приготовительного и пяти нормальных классов, для подготовления учительниц в мусульманские начальные училища» [1, с. 408].

Согласно «Уставу», в учебном заведении устанавливался ежегодный прием учащихся, производимый по результатам экзаменов, к которым допускались девушки всех сословий не младше 12 лет. Срок обучения в школе был определен в пять лет (с приготовительным (подготовительным) классом – шесть лет), с годичным сроком обучения в каждом классе. Вступительные экзамены планировалось принимать два раза в год: с 1 до 10 мая и с 25 августа до начала

учебного года. Причем в приготовительный, первый и второй классы можно было попасть в течение учебного года, с условием, что ребенок при поступлении в училище успешно сдаст дополнительные экзамены по пройденной за этот год программе. В старшие классы учащиеся принимались только в начале учебного года.

В дарельмугаллимате изучались: мусульманское вероучение, история ислама, татарский, русский и арабский языки, арифметика, алгебра, геометрия, география, природоведение, всеобщая, русская и татарская история, анатомия, гигиена, элементарные сведения из физики и химии, общая педагогика, дидактика, история педагогики, методика преподавания русского языка и арифметики, рисование, рукоделие, чистописание и основы ведения домашнего хозяйства, музыка и пение. На основе анализа учебной программы можно определить, что четвертый и пятый классы были педагогическими, так как в них по 4 и 5 часов преподавались педагогические предметы.

По утвержденному уставу в дарельмугаллимате русский язык, историю и географию России планировалось преподавать на русском, а все остальные предметы – на татарском языке.

Учебный год продолжался восемь месяцев, с начала сентября по начало мая. «Устав» установил каникулярное время (зимние – с 25 декабря по 10 января и летние – с мая по август), еженедельный отдых в пятницу, учащиеся также освобождались от занятий во время мусульманских праздников, школьные занятия не проводились и в юбилейные для царского дома даты (дни рождения императора и его близких родственников, восшествия на престол, коронации и т.д.) [8, с. 2].

Сумма годового обучения в данной школе составляла 25 рублей, но 10 % обучавшихся полностью освобождались от нее, а еще 10 % вносили только половину суммы, при этом предпочтение отдавалось бедным и способным девушкам [2, с. 102]. 15 рублей из общей суммы за обучение ученицы должны были выплатить в начале учебного года, а оставшуюся сумму после зимних каникул и до 15 января. Если по каким-то причинам в середине учебного года ученицы были вынуждены прерывать обучение, то выплаченная сумма, в условии занесения ее в записную книжку и выдачи квитанции, не возвращалась. Поэтому прерывать учебный год только по желанию родителей или родственников не разрешалось, для это-

го нужны были уважительные причины и разрешение администрации школы [8, с. 3].

К 1915–1916 учебному году в училище открываются подготовительный, первый и второй классы, где обучаются в общей сложности 62 воспитанницы, а в 1917–1918 учебном году их число возрастает уже до 179. Среди них, кроме местных мусульманок, были и приезжие из Оренбурга, Верхнеуральска, Уфы, Атбасара, Петропавловска и Ташкента [2, с. 103–104].

Таким образом, «Правила 1 июля 1914 года…» открывают путь мусульманскому народу учреждать на официальной основе низшие, средние и высшие учебные заведения для своего народа. Благодаря этим правилам, параллельно с Г. Яушевой дается разрешение «Ниязкулле Вильданову (он же Максютов) открыть в 1-й части г. Троицка среднее частное мусульманское учебное заведение […] для подготовления учителей в мусульманские начальные училища» [1, с. 408]. Спустя год в Казани известная просветительница Ф.Аитова добивается преобразования начальной школы в школу с восьмилетним курсом обучения.

Конечно, эти педагогические учебные заведения не были в состоянии быстро и в полной мере решить задачу подготовки педагогических кадров для мусульманских национальных школ. Прослеживая их историю развития, мы видим, что было приложено немало усилий в решении данного вопроса, и то, что именно они являются положительным результатом борьбы мусульманского народа за свои права. Однако организованные такими большими усилиями и трудом эти школы не успели реализовать возложенные на себя цели и задачи. Работа по подготовке учительниц для мусульманских школ была прервана событиями 1917 года. А после революции 1917 года началось создание новой системы народного образования, которая была в корне отлична от дореволюционной системы.

## ЛИТЕРАТУРА

1. Вестник Оренбургского учебного округа за 1915 год. № 5. – Уфа, 1915. – С. 408.

2. Денисов Д.Н. Становление мусульманского женского образования в конце XIX – начале XX вв. (на примере Оренбургской губернии) // Историко-культурное наследие народов Южного Урала: опыт исследований и практика сохранения: материалы межрегиональной научно-практической конференции. – Оренбург: Издательский центр ОГАУ, 2010. – С. 96–104.

3. Из женского мира // Баянел-Хак. – 1913. – 24 июня.
4. Махмутова А.Х. Пора и нам зажечь зарю свободы! – Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. – С. 163–164.
5. Правила о частных учебных заведениях, классах и курсах Министерства Народного Просвещения, не пользующихся правами правительственных учебных заведений // Вестник Оренбургского учебного округа. – Уфа, 1914. – № 6–7. – С. 567–574.
6. Троицкилы. Әтраф хәбәрләр. [Троицкийда...] // Вакыт. – 1915. – 4 февраль.
7. Хабутдинов А.Ю. Формирование нации и основные направления развития татарского общества в конце XVIII – начале XX веков. – Казань: ГУП ПИК «Идель-Пресс», 2001. – С. 241–242.
8. Яушева Г. Проект программы 6-ти классного мусульманского женского училища г. Троицка Оренбургской губернии. – Троицк: Электро-тип. «Энергия», 1916. – 30 с.

## THE TRANSFORMATION OF THE G.YAUSHEVA'S SCHOOL IN THE TEACHER TRAINING COLLEGE

***Zinnatullina Alsu,***
*Sh.Marjani Institute of History*
*of the Tatarstan Academy of Sciences, Kazan,*
*jamash.00@mail.ru*

The article discusses the main ways to resolve the teacher training issue for Jadid Muslim schools. The processes of reorganization of the school of Gainia Yausheva in a secondary vocational school are revealed, the basic rules for entering the school are covered, attention is paid to the teaching staff of the school.

***Keywords:*** Gainia Yausheva, Tatar intellectuals, Jadid schools, schools charter, pedagogical school, pedagogical education.

УДК 373.3

# МУСУЛЬМАНСКИЕ ШКОЛЫ УФИМСКОЙ ГУБЕРНИИ В НАЧАЛЕ XX В. (ПО МАТЕРИАЛАМ ЗЕМСКИХ ОБСЛЕДОВАНИЙ)

***Ахтямова Алсу Вазиховна,***
*кандидат исторических наук,*
*Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, г. Казань,*
*alsu_was@mail.ru*

Интерес к мусульманскому образованию в начале XX в. возрастает под влиянием обсуждения проекта «О введении всеобщего начального обучения в Российской империи». В статье показана роль земских деятелей в изучении положения начальной мусульманской школы (мектеба), а также начинания земств в сфере народного образования. Источниковой базой для статьи послужили главным образом материалы земских статистических обследований 1912–1913 гг.

***Ключевые слова:*** мектеб, земские управы, материалы земской статистики, земские статистики, Уфимская губерния.

Традиционно учебные заведения у мусульман разделялись на два вида: мектеб (начальная, чаще конфессиональная школа) и медресе (среднее и высшее профессиональное религиозное учебное заведение для подготовки мусульманского духовенства). Как писала газета «Вакыт» («Время»), одна из самых популярных татарских периодических изданий начала XX столетия, эти слова имеют арабские корни и в переводе означают место обучения (преподавания) и воспитания, однако, российские мусульманские учебные заведения главным образом именовались как «медресе», и лишь в последние годы получили распространение названия – «ибтидаи» (начальный) и «медресе» (средний или высший) [16].

Многоэтничный и поликонфессиональный состав населения Уфимской губернии обусловил развитие в крае мусульманских учебных заведений – мектебов и медресе. Данная статья посвящена изучению состояния мусульманских школ (мектебов) Уфимской губернии в начале XX столетия по материалам земско-статистических обследований. Ценность количественного метода исследования в том, что он дает точные сведения об изучаемом объекте.

Однако, как отмечает Г.Б. Азаматова, при работе с земскими статистическими материалами следует учитывать особенности этой группы источников. «Введенные земскими специалистами в оборот, в том числе научный, цифровые данные о мусульманских школах не безупречны в отношении точности», – пишет автор [1, с. 94]. Здесь имели влияние «исследовательский подход» статистиков, неполные, или обобщенные ответы респондентов и т.д.

В работе дореволюционного исследователя С. Рыбакова приведены обобщенные сведения о количестве мусульманских учебных заведений края: в Уфимской губернии функционировало всего 6220 медресе и мектебов [11, с.16]. Примечательно, известный педагог А.А. Еникеев, один из первых советских исследователей истории просвещения края, писал, что по переписи 1856 г. на территории Башкирии во всех башкирских, мещерякских и татарских волостях насчитывается до 1250 мектебов [8, л.70]. В другой работе автора отмечено: «Число мектебе к 1865 г. достигает в одной Уфимской губернии до 354, с общим числом учащихся в нем 15693 человека» [9, л. 35]. Согласно данным современного исследователя Г.В. Савицкого, к 1894 г. в Уфимской губернии действовало 780 мектебов, в Оренбургской губернии – 206, в Уральской области – 118 и Тургайской области – 59 мектебов [12, с. 21].

Школьный вопрос в начале XX века приобретал особую значимость в связи с планами введения всеобщего начального обучения. С началом работы III Государственной думы (ноябрь 1907 г.) Министерством народного просвещения в Думу был внесен целый пакет законопроектов, среди которых наиболее важными были проекты «О введении всеобщего начального обучения в Российской империи», «О начальных училищах» и «О высших начальных училищах» [14, с. 222].

По выражению служащего Уфимской губернской земской управы М.И. Обухова, мектебы – «светильники мусульманского населения» – представляли «полную загадку» для русского общества [6, с. 5]. Инспектор народных училищ Уфимского уезда А.А. Любимов отметил, что «нельзя твердо установить и провести резкую границу между типами: мактаб и медресе» и что «обычное деление мусульманских конфессиональных школ на мектебы и медресе является на практике весьма произвольным», поскольку для этого не имеется «определенного, ясного критерия» [4, с. 1].

В этих условиях перед земскими деятелями встал вопрос о сборе точных и подробных статистических данных относительно местных мектебов. В 1908 г. Уфимская губернская земская управа представила гласным губернского земского собрания доклад по вопросу о школьной сети в отношении мусульманского населения и в заключение выдвинула прошение, в котором отмечалась, кроме всего прочего, необходимость «созвать совещание с представителями земства, министерства народного просвещения, мусульманской интеллигенции, учителей и сведущих лиц для разработки вопроса о типе начальной магометанской школе», что и было удовлетворено [13, с.43–44].

Свою лепту в выявлении количественных данных о мусульманских учебных заведениях губернии внесло совещание при Уфимской губернской земской управе по вопросу о типе начальной общеобразовательной мусульманской школы, состоявшееся в г.Уфе 23–25 мая 1911 г., в котором приняли участие представители уфимских губернских и уездных земских учреждений, министерства народного совещания, а также мусульманской интеллигенции. Участники совещания предложили произвести «расчет по числу приходов», количество которых планировалось выяснить через Оренбургское магометанское духовное собрание. Между тем председатель Уфимской губернской земской управы П.Ф. Коропачинский оставил этот вопрос открытым, поручив подготовить предложения особой комиссии [3, с. 52].

В ходе работы совещания 1911 г. при Уфимской губернской земской управе так называемая «Комиссия, избранная совещанием для обсуждения вопроса об обследовании положения медресе и мектебе» (в составе З. Абызгильдина, Х. Ахтямова, Ш. Кинзекеева, Ш. Махмудова), установила предположительное количество мусульманских учебных заведений в крае. Она отметила, что на 1998 мусульманских приходов в Уфимской губернии приходится около 1500 мектебов и медресе, однако, сколько их по отдельности – неизвестно [3, с.72]. Позднее, в 1913 г. татарская газета «Тормыш» («Жизнь»), издававшаяся в Уфе, сообщала, что в Уфимской губернии насчитывается более 2-х тысяч приходов-махаллей [20].

17 декабря 1911 г. на Уфимском губернском земском собрании было принято решение об изучении состояния начального мусульманского образования в губернии. Желая привлечь к этому делу представителей мусульманского духовенства и интеллигенции, гу-

бернская управа организовала особое совещание 24 мая 1912 г. с их участием, на котором было постановлено избрать комиссию из 10 мусульман и 4 членов управы для выработки программы по обследованию мектебов.

Был совместно разработан опросный бланк (*сөальнамә*), состоявший из 115 вопросов, а также составлено обращение к имамам (*мөрәҗәгатьнамә*). С целью раздачи документов адресатам, основываясь на материалы «Махкамаи Шаргыя», был составлен и список имамов Уфимской губернии, заведовавших мектебами, причем оказалось всего 2144 адреса. Таким образом, каждый имам получил на татарском языке обращение, опросный бланк, форму личной карточки мугаллима, брошюру «Нәрсә ул земство?» («Что такое земство?»). Рукопись брошюры была написана М. Гафури по русским источникам и отпечатана на татарском языке [10, с.5, 123].

К концу 1913 г. были получены заполненные анкеты от 2615 мектебов, однако, как оказалось, из них только около 500 мектебов предоставили достаточно полные сведения, удовлетворяющие членов управы. Кроме того, газета «Вакыт», опираясь на официальные источники Мензелинской уездной земской управы, писала об отсутствии информации о существовании приблизительно 300 махаллей. Примечательно, что из 2615 мектебов 1610 считались организованными (большинство из них мужские мектебы – 1335), 1005 – неорганизованными, т.е. домашнее обучение (преобладали женские (557) и смешанные (337) мектебы) [17].

К маю 1914 г. практически завершается работа по сбору материала, и начинается следующий этап, связанный с переводом анкет на русский язык [19]. Отметим, к этому времени некоторые результаты переписи мектебов были опубликованы [см.: 5]. Обобщение собранного материала было поручено вышеупомянутому статистику отдела народного образования Уфимской губернской земской управы Михаилу Ивановичу Обухову (1871–1943). Итогом его исследований стал изданный в 1915 г. труд «Мектебы Уфимской губернии. Статистический очерк татарских и башкирских низших школ (мектебов) Уфимской губернии по данным исследования Уфимской губернской земской управы 1912–1913 года» [см.: 6].

Согласно данным школьного статистика, в 1912/13 учебном году в губернии насчитывалось 1568 мектебов (зарегистрированных всего – 1579) с контингентом 90936 учащихся, что составляло 5,8% всего мусульманского населения края, однако, они были распреде-

лены неравномерно [6, с. 9, 22, 23]. Примечательно, что из 1568 мектебов только 13 находились в городах, абсолютное большинство – 1566 – в селениях. Таким образом, в Уфимской губернии мектебы были зарегистрированы в большинстве мусульманских приходов (74%).

Подводя итог исследованию, М.И. Обухов отмечает, что более половины из зарегистрированных мектебов ввели у себя светские предметы, перешли к классно-урочной системе преподавания и т.д., и что «старый мектеб, как чисто конфессиональное учебное заведение, отживает свой век». По его словам, старометодных мектебов всего в губернии насчитывается 285 (18,1%), причем в городских поселениях они не имеются, а только в сельских местностях, в основном в Бирском и Стерлитамакском уездах [6, с.30–34, 40]. В то же время было много смешанных школ. Например, в Минзелинском уезде в 1912/1913 учебном году, помимо кадимистских (50) и джадидистских (230) мектебов и медресе, функционировали 576 смешанных типов мусульманских учебных заведений [15].

В заключение М.И. Обухов подчеркивает, что мектеб, может быть, представляет «тот именно тип рационально поставленного инородческого начального училища, которое может войти в общую губернскую школьную сеть на одинаковых правах с начальной русской школой и которым будет удовлетворено мусульманское население» [6, с. 40].

Учебно-воспитательный процесс был организован по таким учебным изданиям, как «Первый учитель» («Мөгаллим әүвәл») и («Мөгаллим сәни») Ахмад Хади Максуди, «Воспитанное дитя» («Тәрбияле бала») Ризы Фахретдина, «История пророков» («Тарихе әнбия») Фатиха Карими, «Наша школа» («Безнең мәктәп») Назипа Думави, «Арифметика» («Гыйлем хисап») Шагидуллы Вахитова и др. [4, с.2–4].

Примечательно просветительское направление в деятельности Уфимского губернского земства. Так, в январском номере газеты «Баянельхак» за 1912 г. сообщалось о выделении Уфимским земством финансовых средств, необходимых для перевода учебных пособий на татарский язык [2, 177 б.]. Кроме того, как писала газета «Тормыш», в 1914 г. благодаря земской инициативе в 8 аулах открылись библиотеки, а в ближайшем будущем предполагалось открытие новых библиотек и курсов для учителей русско-татарских

школ, 13 вечерних библиотек, издание брошюр и книг об образовании и т.д. [18].

В 1916 г. Уфимское губернское земство с целью подготовки учителей-мусульман для русско-татарских и русско-башкирских начальных училищ Уфимской губернии открыло трехгодичные педагогические курсы на основании закона от 1 июля 1914 г. Согласно Уставу курсов, они содержатся на средства Уфимского губернского земства и состоят в заведывании Уфимской губернской земской управы. Программа включала в себя следующие предметы: магометанское вероучение; татарский язык; русский язык; арифметика; алгебра и геометрия; русская, татарская и всеобщая история; всеобщая география и география России; естествоведение (химия, физика, минерология, зоология, ботаника, анатомия, физиология и гигиена); педагогика, психология и дидактика; законоведение; рисование и чистописание; ручной труд и гимнастика; методика предметов начальной школы. На курсы принимались лица обоего пола не моложе 15 лет по итогам устного и письменного испытаний в пределах не ниже программы двухклассных начальных училищ, причем по магометанскому вероучению и татарскому языку поступающие подвергались испытанию по особо установленной программе. За обучение на курсах плата не взималась. По Уставу, пользовавшиеся стипендией от земства учащиеся обязаны отслужить на должности учителя не менее 2 года за каждый год пользования стипендией, в противном случае они должны возвратить земству ту сумму, которую получили в период обучения на курсах [7, л. 7–8 об.].

Уфимское губернское земство разработало и программу для четырехгодичных начальных мусульманских школ (мектебов). Она включала в себя следующие предметы: вероучение (Коран, тяджвид, ильиихал, ахляк, священная история и история ислама), родной язык (чтение, письмо, диктовка, изложение), арифметика (счет, нумерация, 4 действия, именованные числа, правила арифметики и понятие о дроби), история России, география (географические термины, краткая российская и общая география), русский язык (чтение, письмо, разговор, диктовка, изложение), пение (пение стихов религиозно-нравственного характера по мотивам, достойным мектебского духа), гигиена (правила гимнастики и гигиены, относящиеся к правильному росту детей), природоведение (растение, животное, сельскохозяйственное знание), рисование [7, л. 1].

Таким образом, при изучении деятельности мусульманских учебных заведений начала XX в. одним из важнейших источников являются земские статистические исследования. По данным земской статистики, в Уфимской губернии из 2615 мектебов 1610 считались организованными, а 1005 – неорганизованными (т.е. домашнее обучение). В городах функционировали джадидистские мектебы. Более половины из зарегистрированных 1579 местных мектебов ввели светские предметы в программу, перешли к классно-урочной системе преподавания и т.д.

ЛИТЕРАТУРА

1. Азаматова Г.Б. Земское самоуправление в многонациональном регионе России (на примере Уфимской губернии, 1874–1917 гг.): Дис. ... докт. ист. наук / Ордена Знак Почета Институт истории, языка и литературы Уфимского федерального исследовательского центра Российской академии наук. – Уфа, 2018. – 586 с.

2. Ваһапов Н.Ә. Татар вакытлы матбугатында мәгариф һәм тәрбия мәсьәләләренең чагылышы (1907–1916 еллар). – Казан: ТР ФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих институты, 2010. – 188 б.

3. Журналы Совещания при Уфимской губернской земской управе по вопросу о типе начальной общеобразовательной мусульманской школы 23–25 мая 1911 г. – Уфа: Уфимское губ. земство, 1911. [3]. – 74 с.

4. Любимов А. Мактабы и медресе г.Уфы и 1-го района Уфимского уезда. – Уфа, 1914. – 10 с.

5. Магометанские школы (мектебе и медрессе) в Мензелинском уезде Уфимской губернии: 1912–13 учебный год / Собрал и составил по поручению Мензелинского XXXVIII-го Очередного Земского Собрания заведующий хозяйственной частью магом. школ Мензелинского уезда Г.Н. Кильдибяков. – Мензелинск: Тип. Н-в Губанова, аренд. А.И. Вилесовым, 1913. – 78 с.

6. Мектебы Уфимской губернии. Статистический очерк татарских и башкирских низших школ (мектебов) Уфимской губернии по данным исследования Уфимской губернской земской управы 1912–13 года / составил по поручению Управы М.И. Обухов. – Уфа: Электр. тип. «Печать», 1915. – 92 с.

7. НА РБ. Ф. И–137. Оп. 1. Д. 15.

8. НА УНЦ РАН. Ф. 3. Оп. 2. Д. 156.

9. НА УНЦ РАН. Ф. 3. Оп. 2. Д. 433.

10. Обухов М.И. Мектебы Уфимской губернии. Народное образование в Уфимской губернии в 1917 г. / сост. С.В. Вахитов, Ю.В. Ергин. – Уфа: Вагант, 2006. – 136 с.

11. Рыбаков С. Ислам и просвещение инородцев в Уфимской губернии. – СПб.: Синод. тип., 1900. – 28 с.
12. Савицкий Г.В. Начальное народное образование на Южном Урале и Северо-Западном Казахстане в 1851–1917 годах: автореф. дис. ... канд. ист. наук: 07.00.02 / Оренбург. гос. пед. ун-т. – Оренбург, 2004. – 29 с.
13. Систематический сводный сборник постановлений Уфимского губернского земского собрания за 35-летие 1875–1909 гг. (учредительная, 1–35 очередные и 1–42 чрезвычайные сессии): В 3 т. Т. 2. / Сост. П.Н. Григорьев. – Уфа: Электр. губ. тип., 1915. – 938 с.
14. Усманова Д.М. Депутаты от Казанской губернии в Государственной думе России. 1906–1907. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. – 495 с.
15. Уфа губерниясендә мөселман мәктәпләре (Минзәлә земский управасының доклады) // Вакыт. – 1913. – 8 ноябрь.
16. Уфа губерниясендә мөселман мәктәпләре // Вакыт. – 1913. – 10 ноябрь.
17. Уфа губерниясендә мөселман мәктәпләре // Вакыт. – 1913. – 8 декабрь.
18. Уфа земствосы вә мөселманнар // Тормыш. – 1914. – 2 ноябрь.
19. Уфа хәбәрләре // Тормыш. – 1914. – 4 май.
20. Уфа, октябрь 18 // Тормыш. – 1913. – 18 октябрь.

## MUSLIM SCHOOLS OF THE UFA GOVERNORATE AT THE BEGINNING OF THE 20$^{TH}$ CENTURY (BASED ON ZEMSTVO SURVEYS)

***Akhtyamova Alsu,***
*Candidate of Historical Sciences,*
*Sh.Marjani Institute of History*
*of the Tatarstan Academy of Sciences, Kazan,*
*alsu_was@mail.ru*

Interest toward the Muslim education increasing at the beginning of the 20th century during the discussion of the project “On the introduction of universal primary education in the Russian Empire”. The article discusses the situation with the Muslim schools (mektab) and how much Zemstvo influenced to the public education. The research based on the materials of Zemstvo statistical studies for 1912–1913.

***Keywords:*** mekteb, zemstvo councils, materials of zemstvo statistics, Ufa governorate.

УДК 930.2

# МИЛЛИ-МӘДӘНИ МИРАСЫБЫЗНЫ БАРЛАУ ЮЛЫНДА (ТҮБӘН НОВГОРОД ӨЛКӘСЕНЕҢ САФАҖАЙ АВЫЛЫ МИСАЛЫНДА)

***Насыйбуллина Нуридә Шәйдулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты, Казан,*
*nasibullina.nur@yandex.ru*

Мәкалә Түбән Новгород өлкәсе татарларының рухи мирасын өйрәнү мәсьәләләренә багышлана. Тикшерену татар халкының төбәк тарихындагы урынын билгеләү өчен әһәмиятле. Мәкалә 2010 елда Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан татар авылларында уздырылган комплекслы экспедиция вакытында тупланган материалларга нигезләнеп язылды.

***Төп төшенчәләр:*** Сафаҗай, экспедиция, дини белем, ислам, атаклы шәхесләр, Хөсәен һәм Габделгаллэм Фәезхановлар.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре 2010 елда Түбән Новгород өлкәсенә экспедиция оештырды. Экспедиция составында тарихчы-археограф, фольклорчылар, тел галимнәре, музыка һәм сәнгать белгечләре эшләде. Галимнәребез тарафыннан бай материал тупланды. 2011 елның 15 июлендә Пилнә районы Сафаҗай (Красная горка) авылында VIII Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе – «Фәезханов укулары» уздырылды. Бу күркәм чарада халыкка Түбән Новгород өлкәсендә яшәүче милләттәшләребезнең гореф-гадәтләре, тел-авыз иҗаты, сөйләм үзенчәлекләре, археографик һәм эпитафик истәлекләре урын алган «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» дигән сериядә «Милли-мәдәни мирасыбыз: Түбән Новгород» дигән китап тәкъдим ителде.

Җәмгыятебез тормышындагы актуаль мәсьәләләргә багышланган чарада Русия Мөфтиләр шурасы рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин, күрше өлкә-республикалардан, Мәскәүдән, Түбән Новгородтан дин әһелләре дә катнашты. Конференция барышында күренекле галим һәм фикер иясе Хөсәен Фәезхановның ислам мәгарифендәге рефор-

малар концепциясен тикшерү, дөнья сәясәтендә ислам факторының роленә бәя бирү, татар-мишәр берләшмәсенең этник һәм гражданлык бердәйлеген формалаштыру контекстында төп проблемаланы хәл итү мәсьәләләре һәм аларны бүгенге көн күзлегеннән чыгып тормышка ашыру мөмкинлекләре каралды.

Түбән Новгород татарлары зыялы, югары культуралы халык, күп миллионлы татар халкының аерылгысыз бер өлеше. Хәзерге вакытта татарлар бу өлкәнең берничә районында, 35 авылында гомер кичерә. Төбәктәге татарларның саны 50 меңгә җитә. Халкыбызның борынгы данлы тарихы – ул аларның да тарихы булып тора. Нижгар татарларының зур татар тарихы эчендә үз җирле тарихы, милли каһарманнары, халык авыз иҗаты, үз җирле сөйләшләре дә бар. Алар ата-бабаларының бай үткәненә таянып, үзләренең киләчәге турында вакытында кайгырта белеп, үз бөеклеген саклап кала алганнар. Буыннан-буынга халкыбызның үткән юлын дисбе тарткан кебек, күңелләре аша үткәреп, тарихка да, туган җир һәм данлыклы кешеләренә дә ихтирамнарын югалтмаганнар. Көчле рух, Ислам әхлагы, мәгърифәт, гаять зур тырышлык аларны нинди авыр чорларда да татар буларак саклап калган.

Сафаҗай авылы татар милләте өчен ике зур галимне биргән. Аларның берсе – татар модернизмының чишмә башында торган Хөсәен Фәезханов. Бер үк вакытта ул ислам галиме дә, икенче яктан саф дөньяви галим дә булган, Касыйм һәм Кырым ханлыклары буенча бик күп чыганаклар тапкан, беренчел чыганакларны өйрәнгән. Вельямин-Зерновның Касыйм ханлыгы турындагы капиталь хезмәте Хөсәен Фәезханов чыганакларына нигезләнеп язылган. Ә Габделгаллә – Хөсәен Фәезханның энесе. Алар яшәгән XIX гасырның икенче яртысы Россиядә ислахәт, реформалар чоры булган. Габделгаллә Фәезхан шул вакытта банклар белән эш итү, кредитлардан файдаланырга кирәклеге, җирләрне интенсив эшкәртү мөмкинлекләре турында татарча китаплар язган. Бер үк вакытта вакыфлар оештыру, мәдрәсәләрне матди яктан тәэмин итү юлларын (аны дәүләттән алмыйча, мөселманнар үзе тәэмин итәргә тиешлеген) күрсәткән. Габделгаллә Фәезханның Мәрҗани белән хезмәттәшлек итүе дә, беренче татар югары уку йорты ачарга омтылышы да билгеле.

Нижгар – татар мәдәниятенә Кави Нәҗми, Рәшит Ваһапов, Хәйдәр Бигичев, Шәфика Котдусова кебек олы шәхесләр биргән

төбәк тә. Нижгарда ислам динен, мөселман мәдәниятен саклау һәм торгызу актив төстә алып барыла, тулы канлы рухи тормыш кайный. «Мәдинә» нәшрият йорты эшчәнлеге дә Россиядә һәм чит илләрдә яшәүче мөселманнарның игътибарын җәлеп итүдә зур әһәмияткә ия. Биредә ислам тарихына караган фәнни хезмәтләр басыла, Х.Фәезхановның тормыш юлын һәм гыйльми эшчәнлеген яктырткан «Хусаин Фаизхан – первый татарский просветитель» (авторлары А.Юзиев, Д.Мөхетдинов) исемле монография дөнья күрде.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең тикшеренүләрен эченә алган «Милли-мәдәни мирасыбыз: Түбән Новгород» дигән басма күпләрдә кызыксыну уятты. Әлеге мәкаләләрдә татар авылларында табылган борынгы кульязма һәм эпиграфик ядкәрләрне тикшерү нәтиҗәләре турында кызыклы мәгълүматлар китерелә, татар халкы арасында элек-электән бик популяр булган мөнәҗәтләргә, җырларга анализ ясала, әлеге төбәктә таралыш алган үзенчәлекле риваятьләр, легендалар һәм мифологик хикәятләр, музыкаль әсәрләр тәкъдим ителә, Сергач сөйләшен өйрәнү этаплары, аларның үзенчәлекләре, гореф-гадәтләре, йолалары яктыртыла, җирле сөйләшкә башка мишәр сөйләшләре белән чагыштырма анализ ясау нәтиҗәләре җиткерелә, Нижгар татарларына хас кәсепләр, һөнәр төрләре, гамәли сәнгать турында бай мәгълүмат бирелә һ.б.

Соңгы ун елда институтта оештырыла торган комплекслы фәнни экспедицияләр вакытында татар телен, әдәбиятын, сәнгатен, халык иҗатын төрле яклап өйрәнү юнәлешендә зур эш башкарыла, буыннан-буынга тапшырыла килгән шигъри сүзе, бәйрәмнәре, йола-гадәтләре, ягъни фольклоры, милли сәнгатебез үрнәкләре, музыкасы, бәйләү-чигү осталыгы, йорт-каралты бизәкләре, кием-салымы, тел үзенчәлекләре, эпиграфик һәм археографик мирасы – һәрберсе җентекләп барлана-туплана. Мондый чараның төп нәтиҗәсе – халыкта булган матди яисә рухи хәзинәләрне бөртекләп җыйнау, реконструкцияләү һәм халыкның үзенә кире кайтару. Соңгы елларда Россиянең милләттәшләребез яши торган төрле төбәкләренә, Татарстан авылларына һәм хәтта чит илләргә уздырылган экспедицияләр барышында җыйналган мирасны һәм алар хакында галимнәр сүзен китап итеп чыгару да традицион төс алды: «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә дистәдән артык саллы җыентык инде дөнья күрергә өлгерде.

# В ПОИСКАХ ДУХОВНОГО НАСЛЕДИЯ (НА ПРИМЕРЕ ДЕРЕВНИ САФАДЖАЙ НИЖЕГОРОДСКОЙ ОБЛАСТИ)

***Насибуллина Нурида Шайдулловна,***
*кандидат филологических наук,*
*Иститут языка, литературы и искусства*
*им. Г. Ибрагимова АН РТ, г. Казань,*
*nasibullina.nur@yandex.ru*

Статья посвящена изучению духовного наследия Нижегородской области Российской Федерации в историческом аспекте. Исследование актуально с точки зрения определения роли татарского народа в истории края. Статья написана на основе фактических материалов, собранных учеными во время комплексной экспедиции, проведенной в 2010 г. Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова по татарским деревням.

***Ключевые слова:*** экспедиция, конфессиональное образование, религия, ислам, выдающиеся личности, фольклор, татарская литература.

# IN SEARCH OF SPIRITUAL HERITAGE (ON THE EXAMPLE OF SAFAJAI VILLAGE OF NIZHNY NOVGOROD REGION)

***Nasibullina Nurida,***
*Candidate of Philological sciences,*
*G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Kazan,*
*nasibullina.nur@yandex.ru*

The article studied of the history of spiritual heritage of the Nizhny Novgorod region of the Russian Federation. The role of the Tatar people in the history of the region is analised. The article based on the analysis of materials collected by author during a G. Ibragimov Institute’s complex expedition to Tatar villages in 2010.

***Keywords:*** expedition, confessional education, Islam, outstanding persons, folklore, Tatar literature.

УДК 37

# ЯЗУЧЫ ҺӘМ МӨГАЛЛИМӘ МӘХБҮБҖАМАЛ АКЧУРИНАНЫҢ ПЕДАГОГИК КАРАШЛАРЫ (ТУУЫНА 150 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН)

***Абызова Резеда Равил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, Казан,*
*arezeda22@rambler.ru*

Мәкалә татар язучысы һәм мәгърифәтчесе Мәхбүбҗамал Акчуринаның шәхесенә һәм иҗат мирасына багышлана. Автор XX гасыр башы татар җәмгыяте халәтенә караган һәм М.Акчуринаның публицистик хезмәтләрендә яктыртылган төп проблемаларны күрсәтә. Аның 1910–1913 елларда «Шура» журналы битләрендә басылып чыккан тәрбия, ата-ана һәм бала мөнәсәбәтләренә багышланган кайбер хезмәтләрен укучы игътибарына тәкъдим итә.

***Төп төшенчәләр:*** М.Акчурина, мөгаллим, язучы, татар мохите, әхлак, ата-ана, балалар тәрбиясе.

Мәхбүбҗамал Акчурина XX гасыр башында иҗтимагый тормышта барлыкка килгән үзгәрешләр тәэсирендә матбугатка чыккан һәм актив әдәби эшчәнлек белән шөгыльләнгән татар хатын-кыз мәгърифәтчеләренең берсе. Ул 1869 елның мартында элекке Саратов губернасы Димау авылында туа. 1892 елда, киягә чыгу сәбәпле, Самара губернасы Савинка авылына күчеп килә. Анда ул берничә еллар укытучылардан дәресләр алып, белемен үстерә. Соңыннан үзе дә балалар укыта башлый һәм калган бөтен гомерен яшь буынны укыту һәм тәрбияләү эшенә багышлый. 1929 елда Мәхбүбҗамал Акчурина Бакуга күчә һәм 1948 елга кадәр, гомеренең соңгы көннәренә хәтле, шунда яши.

Мәхбүбҗамал Акчурина үзен әдибә буларак та таныта. Аның реаль тормыш вакыйгаларына нигезләнеп язылган «Мишәрләр тормышыннан бер ләүхә», «Шәфкатьсез ата, яки мишәрләр тормышы», «Кыз егълату», «Таш кием», «Хаммал Ягъкуб» исемле хикәяләре дөнья күрә. 1934 елда ул Азербайҗан язучыларының I съездына вәкил итеп чакырыла.

Мәхбүбҗамал Акчуринаның әдәбият һәм тел, хатын-кыз мәсьәләсе, балалар тәрбиясе өлкәләренә караган публицистик мәкаләләре исә «Шура», «Сөембикә», «Мәктәп» журналлары битләрендә басылып чыга. Аның язмалары алдынгы карашлары, ачык фикерләре белән аерылып тора.

«Сөембикә» журналының 1915 елның 9 нчы санында басылып чыккан «Кемдән бу?» исемле мәкаләсендә Мәхбүбҗамал Акчурина хатын-кызга белем, тәрбия бирүне, төрле һөнәрләр өйрәтүне яклап чыга, хатын-кызларның хөр, азат, белемле һәм тәрбияле, җәмгыять өчен кирәкле кеше итеп күрү теләгән белдерә. Башка милләт хатын-кызларының сугышка китү турындагы хәбәрләрен укып, аларның рәсемнәрен күргәч, безнең ис-акылыбыз китә, дип яза ул. Шул хатыннар кебек Ватаныбызга килгән дошман сугышына барырлык көч, җәсарәт[1] бездә булмаса да, хатыннарның белемсезлеге, һөнәрсезлеге белән сугышырга вакыт җиткәнен без аңларга тиешбез, дип үз фикерен белдерә [8].

Мәхбүбҗамал Акчурина «Мәктәп» журналының 1913 елгы 2 нче санында дөнья күргән «Имласызлык» мәкаләсендә шулай ук XX гасыр башында көнүзәк мәсьәләләрдән саналган татар әлифбасы, имла һәм язу кагыйдәләре проблемаларын яктырта. Ул соңгы вакытта бездә яңа имлага нигезләнеп төзелгән бик күп әлифбалар, уку китаплары басылып чыкты, һәм бу бик матур, уңай күренеш, дип яза. «Аларның мөхәррирләре милләт балаларына файда китерү, җиңеллек кылу нияте белән иҗтиһад итәләр, иске ысул белән укыганда туган мәшәкатьләрне йөз, бәлки мең дәрәҗәдә киметәләр. Ләкин шушы язучы әфәнделәр үзләре язган бер китапның бер битендә бер төрле, икенче битендә икенче төрле имла белән язганлыктан, бер үк сүзләр ике төрле хәреф белән күрсәтелгәнлектән, яңа укый башлаган сабый балаларга бик зур уңайсызлыклар килә», ди. Мондый күренешләрдән чыгу юлларын ул укыту ысулларын тәртипкә салуда, мөгаллим һәм мөгаллимәләргә хезмәт итәчәк, аларны берләштерәчәк журналлар нәшер итүдә күрә [7].

Мәхбүбҗамал Акчурина татар халкының авыз иҗаты әсәрләрен җыю, язма әдәби мирасыбызны барлау һәм өйрәнү кирәклеге турында татар хатын-кыз язучылары арасыннан матбугатта беренче сүз башлаган тәнкыйтьче автор буларак та игътибарга

[1] җәсарәт – батырлык, кыюлык

лаеклы [10, 71 б.]. Аның бу мәсьәләләрне яктырткан «Иске әдәбиятыбыз», «Сөбател-гаҗизин» китабы» кебек язмалары «Шура» журналы битләрендә басылып чыга. Әлеге мәкаләләрдә Мәхбүбҗамал Акчурина урта гасырларда иҗат иткән әдипләребезнең эшчәнлегенә хөрмәт белән карау тиешлеге, аларның мирасын саклау турында сүз алып бара. «Башка милләтләрдә борынгы язучыларның көннән-көн кадере, хөрмәте арта бара, – дип яза ул. – Бездә борынгы мөхәррир вә әдипләребезне гаепләүчеләр күбәя. Һәр сүздә нәсыйхәт бар, һәр нәрсәдә зиннәт бар, диләр. Аңлап укылган нәрсә, китап булсын, газета булсын, файдасыз булмас. Көче җиткән кадәр тырышкан борынгы язучыларыбызга рәхмәтләр укып, җир астыннан табылган таш балта, яки чүкеч кебиләрне ташламыйча саклау тиеш булган кебек, аларның әсәрләрен саклау да өстебездә бурыч», – дип нәтиҗә ясый [4].

Борынгы һәм урта гасыр әдәбиятының әһәмиятен Мәхбүбҗамал Акчурина аерым әдәби ядкяр мисалында, татар халкының XX гасыр башларына кадәр яратылып укылган китапларның берсе – шагыйрь Суфи Аллаһиярның «Сөбател-гаҗизин» әсәре мисалында күрсәтә. «Без үзебезнең иске әдәбиятыбыздан хәбәрсез булганга, арлы-бирле укыштыргалап, рус әдәбиятында «Якын булган кешене үзеңне сөйгән кебек сөй», «Йөзеңнең бер ягына суксалар, икенче ягын да куй!» дигән сүзләрен очратабыз да, «никадәр гали һиммәт вә никадәр мәгънәле нәсыйхәт» дип хәйран калабыз. Шул ук сүзләр белән нәсыйхәт кылган Суфи Аллаһияр хәзрәтләрен исебезгә алу кайда, хәтта аның язган китабыннан шомланабыз», – ди [9].

Шул рәвешчә, Мәхбүбҗамал Акчурина үзен халкының язмышы өчен борчылган татар мәгърифәтчелек хәрәкәтенең күренекле вәкиле буларак таныта. Биредә исә без аның ата-ана һәм бала мөнәсәбәтләре, тәрбия мәсьәләләренә багышланган кайбер хезмәтләрен укучы игътибарына тәкъдим итәбез.

## Аталар һәм балалар

Аталар илә балалар арасында була килгән ихтиляф[2] дөнья иске булган кеби иске эштер. Бу ихтиляф бәгъзе вакытта ата илә угылның фикерләре башка булудан чыга, һәр икәве үзенең фикерендә, хыялында нык торып, үз фикерен исбат итүгә тырышып, берәве дөньяны яңа белә башлаганга, вә икенчесе белеп татыганга, бер-

[2] ихтиляф – каршы булу, фикер башкалыгы

берләре илә кушыла алмыйча аерылып китәләр. Бөйлә[3] аерылу ата илә угыл арасында күңелсез эш булса да, куркыныч, кәраһәт[4] сизелми. Гәрчә моның кеби фикер башка булу илә дә күп вакыт ата илә угыл арасында наразыйлыклар[5] күрелеп, байтак кына уңайсызлыклар чыгуга сәбәп булса да, боларның һәр икесен дә каты гаепләргә юл юк. Моны туктатырга тырышу инсанда булган куәт фикрияне туктатырга тырышу буладыр. Мондый фикер аерылу илә булган дошманлыклар әллә никадәр олуг адәмнәр, бөек гакыллы кемсәләрдә дә күрелеп киләдер.

Җир йөзендә булган җинаятьләр арасында атасына кул күтәрмеш, бөек уңайсызлыклар китермеш угылларны байтак кына санарга мөмкин. Мондый угылларга хөкем вә канун алдында җавап бирергә тугры киләдер. Бу кеби җинаятьләр күбрәк вакыт матди җәһәттән булып, аталар илә угыллар арасында каты дошманлыкка сәбәп булуында шөбһә юктыр. Атасын үлдезүчегә[6] һәрбер кешенең күңелендә куркыныч, нәфрәт пәйда була, һәркем кызуланып каты рәвештә аны гаепли. Хәтта аңа иң якын булган кешеләр дә аны гаепләүдән, аңа нәфрәт кылудан үзләрен тыя алмыйлар. Аталарын телләре илә хәкарәт[7] кылучы угылларны да һәркем гаепли. Чөнки дөньяга килүенә сәбәпче булган атасын сөю, хөрмәтләү һәркемнең бурычыдыр.

Балаларын бер нәрсәгә дә санамыйча, «үз көнеңне үзең күр!» дип тәкъдир кулына тапшыручы аталар да гаептән котыла алмыйлар. Хәтта ата дип аталырга да лаек булмаслар. Гаиләсендә туып, митрический дәфтәргә язылган балаларны тәкъдир ишегенә ташларга канун ирек бирми. Мондый аталар аз табылыр. Безем сүзебез балалары хакында «үз гөманларынча[8] һәрбер тиешле эшне эшләгән» аталар тугрысында булачактыр.

Һәркайсы аталар балалары хакында көче җиткән кадәр һәрбер эшне тиешенчә эшләп, тәрбияләрендә тырышдыкларын сөйләп ышандырырга тырышалар. Вә халәнки[9] мондый һәрбер тәрбиясен

---

[3] бөйлә – болай

[4] кәраһәт – чиркәнү, җирәнү

[5] наразыйлык – канәгатьсезлек

[6] үлдезүче – үтерүче

[7] хәкарәт – хурлау, кимсетү

[8] гөман – уй, фикер

[9] халәнки – хальбуки, чынлыкта

тиешенчә тәмамламыш ата тиешле булганның ярымын да эшләмәгән буладыр.

Балалары өчен һәрбер тиеш тәрбияне җиренә китерә алган атаны күз алдына китереп карасак, балалары кечкенә вакытта алар өчен караучы яллый, аларның ашау өчен, кием-салымнарына акчаны аямый, бәгъзе[10] вакыт бала бүлмәсе яныннан үткәндә башларыннан сыйпап яки бер-бер гаеп эшләсәләр, җәза бирә, уку вакыты җиткәч, мәктәпкә җибәрә, андагы кирәкләренә, китапларына да акча аямый, ләкин бу эшләрне башка эшләр арасында гадәти эшләр кеби генә эшләп үтә. Бу балалар яки арадан берсе тугры юлдан чыгып агыр хәлгә очраса, бала үзе гаепле, әгәр дә шундый «көтүдән аерылып китмеш куй» матди җәһәттән чарасыз калса, тәрбияне тәмамламыш ата: «нигъмәт кадере белмәгән – яраксыз, ялкау, башка бала» кеби исемләрен әйтүдә саранлык кылмыйдыр.

Икенчесе – «балаларын сөя торган ата». Мондый ата балаларның уйнап, сикереп йөрдекләрен, үзенең «бәбкә», «наналарының» хәрефләрне дөрес әйтә алмыйча сөйләшүләрен яратып кызык күрә, кечкенә йомшак куллары илә аталарын муеныннан кочаклап үбүләренә җаны рәхәтләнә, аларга төрле уенчыклар, курчаклар алып, үзенең мәхәббәтен изһар[11] кыла, башкалар алдында балалары илә ифтихар[12] итә. Ләкин күп вакытта берничә еллар үтү илә шушы күркәм рәсем башка төскә кереп, борынгы «бәбкәләр», «наналар» урынына «ялкау», «каршы», «тупас» һәм башка шуның кеби сүзләр ишетелә башлый. Балалар үсеп аталарына күңел юанычы, уенчак булудан үткәч, «балаларын сөя торган» атага кызыксыз булып китәләр.

Мөбаләга[13] кылып язылмыш диелсә дә, мондый аталарны аяк атлаган саен очратырга мөмкин. Кечкенә вакытта балаларның тәрбиясе аналар вазифасы идеген һичкем инкяр итми. Аталарның вазифасы исә: балаларның үсүеннән башланып, бигрәк тә дөньяга керә башлаган вакыттыр. Аталарга балаларны кечкенә вакытта ашату гына тиешме икән? Балалар илә аталар арасында башка мөгамәлә, башка карау да булырга тиеш түгелме икән? Аталарның күбесе үсеп җитә торган угыл, кызларын өстләрендә булган авыр

---

[10] бәгъзе – кайбер
[11] изһар – күрсәтү
[12] ифтихар – мактану, горурлану
[13] мөбаләга – арттыру, күпертү

йөк мисалында санап, мөмкин кадәр тизрәк ул йөктән котылырга иҗтиһад итәләр. Шуның өчен дә кызларын тугры килгән кияүгә (гәрчә көфу[14] булмаса да) биреп, угылларны да (гаиләсен тәрбия кылырлык көче булмаса да) өйләндерергә тырышалар. Безнең өстән төшкәч, ничек белдең, шулай тор! дигән кеби. Әмма гаилә сәгадәте дигән нәрсәне уйлаучы аз.

Балигъ булды инде дип баланың тәрбиясеннән әл чигү[15] аталык вазифасын өстән төшерү саналмый, шушы бөлуг[16] яшенә җиткән вакытлар балалар өчен куркынычлы вә агыр улып, аларны ялгыш юлга китүдән сакларга тырышу бигрәк тиеш буладыр. Күп вакытларда гакыллы атаның киңәше, мәхәббәте, мөмкин булса матди ярдәме, агыр, ачы дәкыйкаларда[17] бөек файда китереп, һәлакәткә төшүдән саклады исбат ителмештер.

Балаларның дөньяга килүенә сәбәп булып, ашатып-эчертеп укыту, хәтта бөтенләй зыялы булганча укыту илә дә тәрбиясе тәмам булып, атаның хезмәте бетте хисапланмый. Бәлки балалар бөтенләй инсан хисабына кереп, аяк өстенә баскангача күзәтү аталарның бурычыдыр.

Үзенең аталык вазифасын җиренә китермичә, икенче хатын алып яңадан гаилә төзегән, яки хатыны булып та икенчене алып, әүвәлге хатыныннан калмыш балаларын урнаштырмыйча тәкъдир иреген ташлаучы аталар илә балалар арасында пәйда булган дошманлыклар күзләргә ачык күренеп торадыр. Ата үзенең мәхәббәтен, малын, вакытын яңа гаиләсенә сарыф итеп, теге бичаралар оясыннан очынган кошлар кеби булгач, ничек тә булса интикам[18] алу фикеренә төшеп, явыз уйлар уйларга мәҗбүр булалар. Бигрәк тә аталарының мәхәббәтен, малын болардан алган үги анадан интикам алырга юл эзләп, күп вакытларда олуг җинаятьләр эшләп һәлакәткә төшәләр. Мәхәббәт алдында картлык, яшьлек хисапланмыйча, башның иелдеге һәркемгә мәгълүмдер. Мәхәббәтне яшь хатынына вә аннан туган балаларына сарыф итсә дә, тәрбиядә тигез итү бурычын онытмыйча җәбер итмәскә тиеш. Күп аталар үзләре үлгән соңында да мирас алудан мәхрүм итеп, бар милекне яшь хатынына

[14] көфу – тиң, пар, тиңдәш
[15] әл чигү – читләшү
[16] бөлуг – җитлегү, өлгерү, яшькә җитү
[17] дәкыйка – минут
[18] интикам – үч алу

язып калдыралар, шәригать вә канун билгеләгән хиссадан[19] мәхрүм итәләр.

Балалар явызлыгыннан зарланучы аталарны бик еш очратырга мөмкин. Минем фикеремчә, бозык аталар да аз булмаса кирәк. Атасын үтерүче угыллар каторгага җибәрелә, балаларын һәлак итүче аталар хөрмәткә лаек булып торалар. Икенче хатын алып бетәрбетмәс балаларын куып җибәрүче аталарны, үз баласын үтерүче арасына санарга батырчылык кыламын. Чөнки куылмыш балаларның күбесе һичбер эшкә тотына алмыйча чарасыз калып, яман юлдашлар арасына очрап тәүфыйктан яза да һәлакәт чокырына төшә, яки интикам алып җинаятьче булып һәлак була. Һәрничек булса да, моның һәлак булуына үзенең атасы сәбәпче буладыр.

*(Шура. – 1910. – № 22. – 678–680 б.)*

## Аналар дикъкатенә

Бер нәүгъ[20] аталар кашында[21] балаларның уенчак, икенче нәүгъ аталар кашында агыр йөк идекләрен борын да язылмыш иде. Аналарга килсәк, «балаларының ашау, эчү һәм киемен тиешенчә карамый» дип әйтелсә, һәркайсы ана ачуланып бу сүзне үзенә тәхкыйрь[22] санар, чөнки тереклекнең күп вакытлары бала тәрбиясендәге мәшәкатьләргә сарыф ителә. Ләкин бу мәшәкатьләр тышкы гадәти тәрбиягә генә сарыф кылынудан үтә алмый. Мәгънәви тәрбия хакында аналарның бик азы гына уйлый. Хәтта аның кирәк идеген аңлаучылар да күп табылмас. Төрле шөгыльләр илә чолганмыш аталарга балалар әхваленә танышырга вакыт артмый, тереклек мәйданындагы сугыш аларның дикъкатен җәлеп итеп барлык көчләрен дә үзенә ала. Тереклек мәйданындагы сугышчылар гауга-кычкырышның күплегеннән балаларның фәрьядын[23] ишетми, күзләреннән аккан яшьне сизми калалар. Бу балаларны кыйнамыйлар, җисмәни җәза[24] илә җәзаламыйлар, ләкин мәгънәви тәрбия юклыктан аларның рухлары фәрьяд[25] кыла.

---

[19] хисса – өлеш, үзенә тиешле күләм
[20] нәүгъ – төр
[21] кашында – янында
[22] тәхкыйрь – хурлау
[23] фәрьяд – елау, зарлану
[24] җисмәни җәза – тән җәзасы
[25] фәрьяд – кычкырып елау

Без күп вакытта «урам балалары» дип аталган балаларның әхлаклары бозыклыгына оялып, хәтта җирәнеп карыйбыз. Оялып карасак, бу балаларны гаеп итәргә юл юк. Бу балаларның ата-аналары иң агырлык илә тереклек итә торган сыйныфларга мәнсүбләрдер[26]. Агыр хезмәтләр илә хәлдән таеп, аларга каршы ачуланып һөҗүм иткән фәкыйрьлек-мохтаҗлыкка күкрәк киереп сугышмактадырлар. Ашарга икмәк табудан башканы уйларга аларның вакытлары юк һәм көчләре дә җитми. Шушы мохтаҗлык аркасында балаларының кайда йөрүләрен тикшерү бер тараф торсын, күз алдында эч пошырып тормасалар да, куаналар. Урта сыйныф ата-аналар кечкенә балаларының каршында караучысы бар дип кайда йөрүләрен тикшермичә, тегеләргә караганда ярыйсы гына гаепкә мөстәхикъ[27] булалар. Ул карауччы, фәкыйрьлек аркасында тәрбиядән мәхрүмә булгач, яхшыны яманнан, файданы зыяннан аера алмый. Шуның өчен урам чатларында, су буйларында үзе кеби хадимәләр[28] һәм очраган тәрбиясез егетләр илә сөйләшергә керешә, балалар исә туктап тыңлап торырга мәҗбүр булалар. Мондай булган сүзләрнең ни тугрыда икәнне язарга да хаҗәт юк.

Безем татар хатыннары арасында алты-җиде яшьлек яки аннан да артык кызчыкларны үзләре илә бергә мәҗлесләргә алып бару гадәте бар. Мәҗлес әдәпләреннән хәбәрдар булучыларыбыз дәхи[29] чамалы, арада бәгъзе бер хатыннар шундаен сүзләр ычкындырып җибәрәләр ки: ишеткән ир кешеләр дә кызармый калмаслык була. Кечкенә кызчыклар аңламыйлар дип аналары юкка гына үзләрен юаталар. Тәэссефдер[30], бер дә алай түгел. Чынлап караганда кечкенә балалар без уйлаганнан күп артык сизәләр һәм аңлыйлар. Бер мәртәбә ишеткәндә аңламаса, икенчедә, өченчедә аңлый. Кечкенәләрнең колак-күзе рәсем төшерә торган пыяла мисалында, яхшы-яман ишеткән, күргән нәрсәләр пыялага төшкән кеби гомергә калачактыр.

Шәһәр балаларына килсәк, шул ук күңелсез рәсем. Нинди генә шәһәргә карасак та, кич сәгать 10–11ләрдә бакчаларда кечкенә балаларны ияртксән хадимәләрне күрергә мөмкин. Ачык юлларда

---

[26] мәнсүб – кагылышлы, мөнәсәбәтле булу

[27] мөстәхикъ – лаеклы

[28] хадим – хезмәтче, ялчы

[29] дәхи – тагы

[30] тәэссеф – үкенеч

ярыйсы гына йөрсәләр дә, бераз караңгы почмакларда башка рәсем вә башка кыланышлар күрелә. Шушы кыланышларга кат-кат карагач, киләчәктә татлы өмедләр илә көтә торган милләт җимешләренең чәчәкләр ачылмастан борын ук кырау тиеп читләре карала башлый.

Без аналар барлык көчебезне сарыф итеп шундаен иртә тия торган кыраулардан киләчәктәге ышанычыбыз булган чәчәкләребезне сакларга иҗтиһад итмәсәк, шушы кыраулар ачылмаган чәчәкләрнең әүвәл тирәләрен каралтып, ахырында ачылып җиткәндә туңдырса, ул чәчәктә җимеш өмеде калмыйдыр. Өйдә кунак булганда мәҗлес әдәпләреннән хәбәрдар кемсәләр катында балалар катнашса да, зыян юк, бәлки кеше арасында үзләрен тотарга өйрәнергә ярдәме булачак. Әмма мәҗлес әдәпләре белмәгән кунаклар катыннан, ир-хатын, мөселман-рус булсын, кечкенәләрне ерак тоту тиеш идегендә шөбһә юк. Хадимәләр илә балаларны күз артына җибәреп, хәясез[31] улып, әхлаклары бозылуларына сәбәп булудан, яшьләремездән көтә торган өмедләребезнең тамырына балта чабудан саклануга тырышу вазифабызны онытмаска һәркаюмызга ляземдер.

*(Шура. – 1911. – № 4. – 119–120 б.)*

## Тәрбия вә җәза

Җимеш агачлары сугармаенча[32], ашламаенча тәмле җимеш бирмәдекләре кеби, адәм балалары да тәрбиясез чын адәм була алмыйлар. Адәм балаларының тереклегендә тәрбия иң мөһим урын тотадыр. Шуның өчен дә балаларның тәрбиясе ата, ана, хәтта бөтен милләт өстендә иң олуг, иң агыр хезмәт саналадыр. Тәрбиянең мәгънәсе җисмәни һәм мәгънәви көчне көннән-көн арттыруга тырышудыр. Балалар тәрбиясе үзе генә чиксез олуг гыйлемлектер. Вә халәнки мөрәбби[33]* һәм мөгаллим әфәнделәр моңа күп әһәмият бирмиләр. Балалар тәрбиясендә мөрәбби вә мөгаллим әфәнделәрнең әхлагы, табигате тәрбия вә тәгълим[34] кылына торган балаларның

---

[31] хәя – оят, тыйнаклылык

[32] сугару – су сибү

[33] мөрәбби – тәрбияче

* Мөрәббидән морад бигрәк ата-аналардыр (М.Акчурина искәрмәсе – *Р.А.*).

[34] тәгълим – укыту, өйрәтү

гакыл һәм әхлакларын аңлап, шуңа күрә сөаль вә бәян кылуларындагы осталыклары иң кирәкле урынны ишгаль[35] итәдер. Шушы тәрбия вә тәгълим бабына мөрәбби вә мөгаллим әфәнделәрнең үз сүзләрен тыңлату, ялкаулыкны качырып теләгән юлдан барырга ярдәм итә дип саналмыш җәзалар да керәдер.

Тәрбия бабында балаларга кылына торган җәзалар мәдәни халыкның дикъкатен җәлеп иткән дәрәҗәдә башка эшләр җитә алмыйлар. Моның хакында алты-җиде гасырлар борын бәхәс ителгән кеби, хәзерге заманда һәм бәхәс ителәдер.

Хәзрәт Гайсәдән 600 ел чамасы элек булган юнан[36] голямасыннан философ Пифагор балалар тәрбиясендә җәзага ябышмыйча, кирәк юлдан баруны гадәтләндереп табарга тәүсыя[37] кылмыштыр. Бер нәрсәгә яки бер эшкә гадәтләндереп, ягъни куркытмый, аптыратмый йомшаклык илә кат-кат төшендергәч, кешенең табигатенә тәэсир итү мөмкин идекне борынгы философ сөйләп, гадәтләнү икенче табигать, димештер.

Юнан голямасыннан Сократ һәм җәзага каршы торып, балаларның тырышуларын, фикерләрен төрле сөальләр илә уйгатып, мөмкин кадәр миләрен, гакылларын эшкә боеру илә тәүсыя кылмыштыр. Болардан башка һәм күп мәшһүр галимнәр җәзага каршы тормышлар. Җәза аркасында балаларда гакыл, фикер тупасланып, әсирлек, коллык, куркаклык хисе урнашып, мөгаллим һәм мөрәббиләрнең дә икътидарсыз[38] идекләре исбат ителәдер.

Тәрбия тәгълим бабында ике төрле җәза йөртелү мөмкин табылмыштыр. Беренче кылынмыш җәза – баланың фикерен уйгатырлык булу. Икенче – баланың сәламәтлегенә зарар килмәү һәм тәхкыйрь[39] хисе булмассызлыктыр. Кирәк тән вә кирәк мәгънәви җәза булсын, шарт икәвендә дә бердер.

Бу мәкаләдә мәгънәви җәзаны куеп, хифзыссыйхәт[40] ноктаи назарендәге[41] тән җәзасы хакында бәхәс итеп, баланың сәламәтлегенә ничек тәэсир иттеге тугрысында язачакмын.

---

[35] ишгаль – биләү

[36] юнан – грек

[37] тәүсыя – киңәш бирү

[38] икътидар – көч, куәт

[39] тәхкыйрь – хурлау, мыскыл итү

[40] хифзыссыйхәт – сәламәтлекне саклау һәм аның юллары

[41] ноктаи назар – караш

Гаиләләр эчендә һәм мәктәпләрдә аяк атлаган саен очрый торган почмакка кую җәзасы: бала ни булса зыян итте, зурларның сүзен тыңламады яки кушкан йомышка бармады, ялкауланды, дәресне хәзерләмәде – зурларның фикеренчә, иң җиңел булган җәза почмакка хөкем итүдер. Хифзыссыйхәт ноктаи назарендә шушы «зарарсыз җиңел җәзадан» әллә никадәр олуг зарар килү мөмкин. Бер урында селкенмичә озак басып торудан бәдәндәге[42] канның хәрәкәте кирәгенчә булмыйча, аяклардагы тамырларга артык китә, басып тору күпме озак булса, кан төшү һәм шуңа карый. Болай басып торулар еш-еш булганда, кан хәрәкәте тиешенчә булмыйча, балаларның башында кан азлык авыруы пәйда буладыр. Бигрәк тә бу җәза каны аз балаларга яман тәэсир итә. Каны аз балаларны басып тору җәзасына хөкем итүне ташларга мөмкин булмаса, вакытны кыскартуга тиештер.

Тагы моңа охшашлы гаилә эчендә аналар тарафыннан бирелә торган җәза бардыр ки: ул да аяк үзрә[43] ашатудыр. Йомшак күңелле аналар үзләренең бәгырь ярасы булган балаларын бөтенләй ашсыз калдыруга көчләре җитми дә аяк үзәрендә ашарга бирәләр. Әмма сөекле балаларына никадәр зыян китердекләрен тоймый калалар. Ашау вакытында һәрбер әгъзалардагы кан хәрәкәте тиешенчә булып, мигъдәнең[44] пешерүенә кирәк булган юешлек аерылсын өчен бәдән бигрәк тынычлыкка мохтаҗ буладыр. Югарыда әйткәнчә, бер җирдә басып торганда, кан тиешенчә хәрәкәт итә алмаганга, ашказаны да үз хезмәтен җиренә китерә алмыйдыр.

Гаилә эчендә һәм мәктәпләрдә бирелә торган җәзалардан тагы берсе – тез өстенә куюдыр. Селкенмичә басып торудан кан тиешенчә хәрәкәт итә алмагач, тез өстендә бигрәк тә булмый. Тез өстендә торудан каны аз балаларның аяклары оеша яки бик каты авырта, хәтта җәза вакыты тулгач та озак вакытка тартыла. Иске ысул мәктәп-мәдрәсәләрдәге хәлфәләр моның илә генә канәгать итмичә, идәнгә борчак, карабодай яисә тоз сибеп шуның өстенә тезләндермешләр. Хәзерге заманда һәм караңгырак мәктәпләрдә шундый вәхшәтләр бетеп җитмәгән.

Болардан соң суктыру җәзасына килик. Кирәк чыбык, кирәк камчы булсын, моны татыган баланың күңелендә мөрәббисенә,

---

[42] бәдән – гәүдә, тән
[43] аяк үзрә – аяк өсте
[44] мигъдә – ашказаны

мөгаллименә, хәтта ата-анасына булсын, мәхәббәте, хөрмәте борынгы кеби булыр микән? Кыйналган соңында бала сүзне тыңласа да, күп куанырлык урын юк...

Йөзгә сугу, колактан тарту кеби һәр аяк атлаган саен очрый торган җәзалардан балаларның сәламәтлегенә никадәр зыяннар килдеген уйлаучы да юк. Колактан каты тарту илә берничә вакытка, хәтта бөтенләй саңгырау итәргә мөмкин. Йөзгә вә башка сугудан, чәчтән тартудан баш авыруы һәм гасаби[45] авырулар пәйда буладыр. Хифзыссыйхәттән бихәбәр аналар үзләре балаларын авыруга сабыштыралар яки хәлфәләр кулыннан авыру була да, җен зарары тиде дип, өшкерү-төкерүләр илә яңадан җәзалый башлыйлар.

Мәктәп-мәдрәсәләрдәге (хәтта монтазам[46] рус хөкүмәт мәктәпләрендә) ашсыз калдыруны санга да алмыйбыз, җәзага да хисап итмибез. Вә халәнки балаларны ашсыз калдыру җәза гына түгел, газап кылу булып чыгадыр. Нинди олуг җинаять ияләре дә һичбер вакыт ачлык җәзасына хөкем ителмәгәндә, мәктәп-мәдрәсәләрдәге милләт өмеде шәкертләр ачлык җәзасына хөкем ителәләр. Боларның гөнаһлары никадәр олуг булса да, катилләрдән[47] яки башка зур җинаять ияләреннән артык түгелдер.

Мөрәбби вә мөгаллим әфәнделәр һәм ата-аналарның күбрәге тәрбия-тәгълим вакытында бәгъзе балаларны сугудан, җәзадан башка юлга салу мөмкин түгел дип әйтүгә көчләре җитә. Әмма бәдәнгә зыян китерә торган җәзалар илә рухны дәвалап, тугры юлга салу шөбһәледер.

*(Шура. – 1911. – № 16. – 500–501 б.)*

## Мәхәббәт дәресләре

Җир йөзендә булган һәрбер нәрсәгә гыйбрәт илә караганда, бер тереклекне фида[48] кылу илә бик күп тереклек хасил булганны күрергә мөмкин.

Күз алдыбызда ачылган гөл чәчәге бер-ике көн үтү илә йомшарды (мишәрләр тәгъбиренчә[49] – пыжыды), гакыйбәт[50] җиргә ко-

---

[45] гасаби – нерв
[46] монтазам – тәртипкә салынган, тәртипле
[47] катил – үтерүче
[48] фида – корбан итү
[49] тәгъбир – аңлату
[50] гакыйбәт – ахыр, соң

елды. Дикъкатьләп карагач, түгелгән чәчәкнең сабагында бик күп вак кына орлыклар күренә. Чәчәк үзен фида кылып, күкрәгендә тәрбияләп күп яңа чәчәкләргә тереклек калдырган. Йорт хайваннарыннан алып хәтта иң ерткыч җанварлар да балаларын имезеп тәрбия кылган вакытларында ана мәхәббәтенең раст[51] вә мөкаддәс[52] мәхәббәт икәнендә кем шөбһә итәр? Ерткыч вә кан түгүче җанварларга карагыз: баласын никадәр шәфкать илә имезә, ялый, назлата, юата, җылыта, дошманнан саклауда үз җанын фида кыладыр.

Адәм балаларында ир илә хатынның икәвеннән әүвәлге бала дөньяга килсә, икедән өч булды, янә бер адәм баласы артты, дибез. Аллаһы Тәгалә баланы көчсез, күп елларга ярдәмгә мохтаҗ итеп бирүе аналар калыбында мәхәббәтне арттыру өчен булса кирәк.

Хайван һәм ерткыч җанварларның балалары адәм балаларына караганда күп дәрәҗә көчле, ярдәмгә дә азрак мохтаҗлардыр. Берничә айлар үтү илә баласы анасын, анасы баласын танымаслык булалар. Адәм балалары исә бөтенләй башка: мәхәббәт орлыклары тишелеп, яшәреп күркәм гөлләргә әверелүгә байтак вакыт кирәк булдыгыннан, Җәнаб[53] бары ярдәмгә мохтаҗ көчсез балалар һибә[54] кылмыштыр.

Тәгълим юлының да башы бала тәрбиясеннән башланып, әүвәл дә исә мәхәббәттер. Тәгълим юлы дигәч тә, яңа туган баланы тәгълим кылу аңлашылмасын. Бәлки дөньяга яңа килгән көчсез бала олуг мәгънәле мәхәббәт дәресе бирүдә анасына мөгаллим буладыр.

Иң әүвәл бала анасына сабыр вә сәбат[55] дәресе биреп, аның йөрәгендә элеккедә булмаган һәм каләм илә тәгърифе[56] мөмкин түгел хисләр уятадыр. Йоклаган баласының башы очында утырган ананың йөзендәге нәзек тәбәссем[57], чиксез мәхәббәт, татлы йокысын, бәлки җанын фида кылуга хәзерлек кайдан килә? Боларның барысы көчсез балачыкның анасына өйрәткән мәхәббәт дәресенең әсәредер[58].

---

[51] раст – дөрес, рас, чын
[52] мөкаддәс – изге, бөек, хөрмәтле
[53] Җәнаб – Аллаһы Тәгалә
[54] һибә – бүләк
[55] сәбат – чыдамлылык, ныклык
[56] тәгъриф – аңлату, белдерү
[57] тәбәссем – елмаю, көлемсерәү
[58] әсәр – йогынты, тәэсир

Ана баласын күкрәге илә имезеп тәрбия кыла, димәк үзен фида кылып башкага тереклек бирә, шушы олуг дәресләрне көчсез балачыкның өйрәтүе гаҗәп имәзме? Шуның өчен дә дөнья йөзендәге раст мәхәббәт һәм адәмчелекнең башы ошбу дәрестән башланган димешләр.

Яңа туган балачыкларыбызның дәресен тыңлыйбыз, имезәбез, татлы йокыларыбызны калдырып уяу торган төннәребез хисапсыз була, балаларыбыздан берәве авырса, йөрәгебез янып хәсрәтләнәбез. Бу эшләрне кимчелек кылмый үтәсәк, үзебезне бәхетле саныйбыз. Балаларыбыз уку яшенә җиткәч, шул сәбат вә сабырыбызны югалтмый мәгънәви тәрбияләренә ярдәмче булсак, дөнья вә гакыбәдә[59] бәхетле булыр идек. Бу вакытта балаларыбыз әүвәлгегә караганда көчлерәк булсалар да, шулай ук ярдәмгә мохтаҗлардыр. Монда инде аталар илә аналар бергәләшеп гыйлемгә, укытуга бар көчләрен сарыф итәргә, мәгарифтән мәхрүм калган балаларның иң зәгыйфь вә иң көчсез идеген хәтердән чыгармаска, мәхәббәт орлыкларыннан гөл чәчәкләре үстерүдә кимчелек кылмаска тиештер. Наданлык – караңгылык идеген инкяр итүчеләр күп табылмаса кирәк. Дөнья йөзендә булган бозыклык вә җинаятьләрнең дә күбесе мәгънәви тәрбия юклыктан киләдер.

Гыйлем укыту ягына килгәндә, безем татар халкы «байлыгыбыз юк, шуңа күрә балаларыбызны укыта алмыйбыз» диләр. Уку өчен дөньяда ялгыз байлык шарт булса, барлык бай балалары галим булып, фәкыйрьләрнең бары надан калырлар иде.

Матди җәһәте тәэмин кылынып үз иҗтиһады[60] кәмалендә[61] булган шәкерткә уку асан[62], сәламәтлегенә дә зыян килмәве шөбһәсездер. Ләкин безем татар милләте арасында мондый бәхетле шәкертләр бармак илә генә санарлык. Байлык булса, я атада, яки балада сәбат, иҗтиһад булмый. Истигъдад[63], иҗтиһад булса, байлык булмый.

Ике ел борын Саратов шәһәренә бардыгымда Н. нумерлары илә күрше йортның капкасы төбендә урамда ундүрт-унбиш яшьлек кап-кара чәчле, ялан аяклы яһүди баласының дәрес хәзерләп

---

[59] гакыб – соң, нәтиҗә
[60] иҗтиһад – тырышу, эшкә күңел биреп эшләү
[61] кәмаль – житешкәнлек, өлгергәнлек
[62] асан – ансат
[63] истигъдад – сәләтлелек

утырдыгын күрдем. Сентябрьнең башы, көннәр җылы булганга, болай чыккандыр дип уйладым. Икенче, өченче көндә дә шулай булгач, нумерлар иясенең кызыннан сорадым да: «Ул Абрамка, реальный шәкерде, өйләре бик кечкенә, дәхи дә биш-алты вак балалары бар, өйдә урын юклыктан, урамда дәрес хәзерли», – диде. «Атасының кәсебе ни нәрсә?» дип сорагач, сәгатьләр төзәтүче дип җавап бирде.

Бу сүзләр минем дикъкатемне җәлеп итеп, атасының ни төсле икәнен күрәсем килде. Икенче көн бәйрәм булганга, Абрамканың атасы да урамга чыкты. Арык кына, килешсез кыяфәтле бер яһүди. Өстендә байтак киң, иске генә бишмәт (талчуктан[64] алынган булса кирәк). Бу фәкыйрь яһүди илә баласының хәленә карап, раст ата, иҗтиһадлы бала идекләрендә шөбһәм калмады. Кечкенә, тәтенле бүлмәдә ярым ач торып, баласын мәгарифтән мәхрүм итмәскә тырышуы шаян[65] гыйбрәттер.

Йөрәк пәрәсе балаларыбызны киләчәктә аяк астына тапталып хур булудан саклау безем бурычыбыздыр. Гыйлемнән, укудан мәхрүм итсәк, бурычыбыз үтәмәгән булып, балаларыбыз кашында һәм Аллаһы Тәгалә хозурында оятлы булачакбыз. Балаларыбыз безгә үгрәткән мәхәббәт дәресен җиренә китерү һәркаюбызга ляземдер.

*(Шура. – 1912. – № 6. – 183–184 б.)*

## Балаларның уеннары һәм уенчыклары

Балаларның уеннары вә уенчыклары тугрысында фикер йөртергә, ислях[66] кылырга безгә дә вакыт җиткән булса кирәк. Уенчыкларның нәүгесе бик күп булып, боларның ниндәе файда, ниндәе зарар бирә идекне уйлау, карау аналар вә мөрәббиләр вазифасыдыр. Тәәссефкә каршы, без һәркаюбыз файда вә зарарны уйламыйча, бердән: балаларыбызның күңелләрен табу нияте, икенчедән: уенчыкларга әһәмиятсез нәрсәләр дип карарга гадәтләндегебездән, күренгән бер уенчыкны алып бирәбез. Хәлбүки балаларның сәламәтлеге һәм тәрбияләре өчен болар мөһим урынны тоталар. Шуның өчен боларны сайлап бирү тиеш.

Мөхтәрәм вә мөхтәрәмә «Шура» укучылары илә киңәшмәкче булып уен вә уенчыкларны берничә бүлеккә аерам:

---

[64] талчук – сөйләм телендә: иске-моски сатыла торган базар (*Р.А.*)

[65] шаян – тиешле дәрәҗәдә

[66] ислях – үзгәртү, реформа

1) Кай вакытта уенчыклар файдалы, ничә яшьтә алар хаҗәт.

2) Кыз балалар илә ир балалар арасында уен вә уенчыкларның аермасы.

3) Курчак вә алар илә уйнауның файда вә зарарлары.

Бала дөньяга килгәч, өч-дүрт һәфтәдә[67] көлә башлый. Менә шул вакыттан ук анасы һәм башка якынлары көлдерергә тырышып, баланың кечкенә миенә тыныч бирмиләр. Кечкенә вакытында бала никадәр тыныч ятса, бәдәне, мие шулкадәр сәламәт буладыр. Балаларның киреләнүе яшь ярым, ике яшькә җиткәндүк гасаби авыруга мөбтәля булуы[68] (халык телендә җилләнә дип тәгъбир кылына) кечкенә вакытта көлдерү, тирә якка карарга көчләү сәбәбеннән, мие зәгыйфьләнүдән киләдер. Баланың бу хәленә ата-аналар хафаланып, каюсы өшкерә вә каюсы белер-белмәс дарулап, тагын миен тынычсызландыралар. Яшь баланың нервалары зәгыйфьләнгәч, аны китәрү җиңел түгел.

Яңа туган баланың тик бәдәне сәламәт булуга игътибар итү илә кифаяләнеп[69], ике-өч айлык балага гакыл өйрәтү тиеш имәс. Сәламәт баланың егълавына да ул кадәр эч пошмаска кирәк. Бала караучының белер-белмәс селкетеп-тирбәтеп юатуыннан ятып егълавы файдалыдыр. Сәламәт бала күп егъласа, күкрәге киң була. Өч-дүрт айлык булгач ук баланың башы тугрысына бишеккә чуар нәрсәләр бәйләү гадәте шулкадәр киң урын алган ки, һичбер бишек ансыз булмас дисәм, мөбаләгага түгелдер. Сатып алган чуар уенчык булмаса, төрле чуар чүпрәкләр булса да тагылып куеладыр. Бала яткан җирендә шушы чуар нәрсәне тотмакчы була, юана, хәтта йоклап киткәч тә, кулларын суза. Моннан беленә ки: баланың кечкенә мие йокыга киткәч тә тынычланмаган, һаман эшләп торадыр. Өч айга кадәр балага асла[70] уенчык кирәкми. Дүртенче айга чыккач, теш итләре кычыта башлаганга, сөяк хилка[71] (кольцо) кирәк буладыр. Хилканы бала авызына кабып, теш итләре илә кыса. Теш итләре кычытканга күрә балага рәхәт бирә. Икенчедән, теш итләре ярылып, тешләрнең тиз чыгуына ярдәм итә. Моннан соң кечкенә

[67] һәфтә – атна
[68] мөбтәля булу – дучар булу
[69] кифаяләнү – канәгатьләнү
[70] асла – һич, бер дә
[71] хилка – божра, түгәрәк

генә резин көррә[72] (мяч) хаҗәт була. Бала көррәне бәреп җибәрә, янындагылар алып биргәч, янә бәреп җибәрә дә бала рәхәтләнеп көлә һәм кул итләренең көче артуга файда бирә. Кечкенә кыңгырау зыянсыз булачак.

Бер яшь тулганда сәламәт бала йөри һәм азлап сөйләшә башлый, бу вакытта балага кечкенә хайван сурәтләре бирергә ярый. Тиен, арыслан, аю, бүре, каплан кеби ерткыч җанварлар сурәте булмасын. Өй эчендә күзенә һәр көн, бәлки һәр сәгать күренә торган мәче, йортта булган ат, сыер, куй, кәҗә, ат, кошлардан тавык, каз, үрдәк, күгәрчен, чыпчык кеби таныш нәрсәләр булсын. Балага боларның терекләрен күрү кыен булмаганга, кечкенә мие боларга ияләшә. Югарыда язылган җанварларның, бөркет, лачын, карчыга, тутый кеби кошларның терекләрен күрү җәгърафия укыган вакытта да балаларның күбесенә [...] булмыйдыр. Бу язылган уенчыклар илә утырып уйналганга, йөгереп, селкенеп уйнар өчен тагы да резин көррәгә хаҗәт төшә.

Югарыда язылган хайван, кош сурәтләрен балага бердән бирелсә, каюсына бигрәк кызыгырга белми дә, ихласы тиз кайта. Берәмләп бирелгәндә, кызыкканнан кызыгып уйный. Яз көнендә хайванчыкларны төяп йөртергә, ком ташып уйнауга кечкенә агач арбачыклар булса, бала утырып уйнамый, һаман йөри, селкенә, шуның илә күңеле ачыла, иштиһасы[73] арта, йокысын тыныч йоклый. Яз көннәрендә мөмкин кадәр балаларны ачык һавада уйнату тиеш.

Дүрт яшькә җиткәч, азлап-азлап рәсемнәр күрсәтү мөмкин. Бишкә җиткәч, каты кәгазьдән яки агачтан ясалмыш кечкенә кирпечләр файда бирәчәк. Кирпечләрдән балалар төрле биналар ясыйлар. Калын кәгазьдә ясалган төрле шәйләрне[74] кисеп, үзләре дә кәгазь өстенә ни белсә, рәсем кеби ясыйлар. Алты-җиде яшьтә әлифба хәрефләре язылган калын кәгазь кисәкләре яисә хәрефләр язылган агач кисәкләре бирелсә, һичбер мәшәкатьсез уен арасында хәрефләр таныргa, хәтта укырга өйрәнәләр. Җиде-сигез яшендә балаларга кыш көне кечкенә чана (салазка) илә шуып уйнау, аннан югары киткәч, каток шуу вакыты да килеп җитә.

Кәгазь, агач кирпечләре илә уйнаганда яисә ниндәй булса рәсем кеби нәрсәләр ясап маташканда, балаларга камил азатлык

[72] көррә – туп
[73] иштиһа – аппетит
[74] шәй – әйбер

бирү тиеш. Әгәр: «Аны ясама, менә моны яса» дип һаман күрсәтеләп торылса, бала үзен азат сизмәгәч, гасабилана. Икенче: күрсәткән нәрсәне яки рәсемне генә ясарга өйрәнгән бала киләчәктә дә үз алдыннан һичбер нәрсә эшләргә көче җитми. Юлбашчы булмаса, бер каршы алга атларга курка.

*(Шура. – 1913. – № 20. – 631–632 б.)*

ӘДӘБИЯТ

1. Акчурина М. Аталар һәм балалар // Шура. – 1910. – № 22. – 678–680 б.
2. Акчурина М. Аналар дикъкатенә // Шура. – 1911. – № 4. – 119–120 б.
3. Акчурина М. Тәрбия вә җәза // Шура. – 1911. – № 16. – 500–501 б.
4. Акчурина М. Иске әдәбиятыбыз // Шура. – 1911. – № 16. – 508–510 б.
5. Акчурина М. Мәхәббәт дәресләре // Шура. – 1912. – № 6. – 183–184 б.
6. Акчурина М. Балаларның уеннары һәм уенчыклары // Шура. – 1913. – № 20. – 631–632 б.
7. Акчурина М. Имласызлык // Мәктәп. – 1913. – № 2. – 55–57 б.
8. Акчурина М. Кемдән бу? // Сөембикә. – 1915. – № 9. – 7–9 б.
9. Акчурина М. «Сөбател-гаҗизин» китабы // Шура. – 1917. – № 8. – 181–182 б.
10. Өмет йолдызлары / Төз. М. Гайнуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 71 б.

## ПЕДАГОГИЧЕСКИЕ ВЗГЛЯДЫ ТАТАРСКОЙ ПРОСВЕТИТЕЛЬНИЦЫ МАХБУБДЖАМАЛ АКЧУРИНОЙ (К 150-ЛЕТИЮ СО ДНЯ РОЖДЕНИЯ)

***Абызова Резеда Равиловна,***
*кандидат филологических наук,*
*Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, г. Казань,*
*arezeda22@rambler.ru*

Данная статья посвящена личности татарской писательницы и просветительницы Махбубджамал Акчуриной. В работе автором рассмотрены основные проблемы, касающиеся положения татарского общества в начале XX века и нашедшие отражение в публицистических трудах М.Акчуриной. Вниманию читателей также предлагается ряд ее статей, которые в

1910–1913 гг. были опубликованы на страницах журнала «Шура» и посвящены вопросам воспитания, проблемам взаимоотношений родителей и их детей.
***Ключевые слова:*** М.Акчурина, педагог, писательница, татарское общество, нравственность, родители, воспитание детей.

## PEDAGOGICAL VIEWS OF THE TATAR ENLIGHTENER MAHBUBJAMAL AKCHURINA (TO THE 150TH ANNIVERSARY OF THE BIRTH)

***Abyzova Rezeda,***
*Candidate of Philological sciences,*
*Sh.Marjani Institute of History*
*of the Tatarstan Academy of Sciences, Kazan,*
*arezeda22@rambler.ru*

This article is dedicated to the Tatar writer and enlightener Mahbubjamal Akchurina. The author examined the main problems of Tatar society at the beginning of the 20th century and how they reflected in the writings of M. Akchurina. As the attachment you will see some examples of her articles about education, the problems of relations between parents and their children, published in 1910–1913 in the “Shura” magazine.
***Keywords:*** M.Akchurina, teacher, writer, Tatar society, morality, parents, moral upbringing of children.

# II. СОВРЕМЕННОЕ СОСТОЯНИЕ НАЦИОНАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ

УДК 37

## БҮГЕНГЕ КӨНДӘ БАЛАЛАРГА МИЛЛИ ТӘРБИЯ, ДИНИ БЕЛЕМ БИРҮДӘГЕ ПРОБЛЕМАЛАР ҺӘМ АЛАРНЫ ЧИШҮДӘ «АК МӘЧЕТ» ТӘҖРИБӘСЕ

***Шәйхевәлиев Рөстәм Шәйхеразый улы,***
*«Ак мәчет» мәдрәсәсе, Яр Чаллы,*
*imam@akmechet.ru*

Мәкаләдә татар мәктәбен үзгәртеп кору мәсьәләсе күтәрелә. Автор фикеренчә, реформа бер үк дәрәҗәдә укыту һәм тәрбия барышында чагылыш табарга тиеш. Татар халкының мәгариф тарихына караган мәгълүматларга нигезләнеп, белем һәм тәрбия бирүгә яңача караш кирәклеге ассызыклана. Мәктәпне үзгәртеп коруда фәнни-тикшеренү эшләренең зур әһәмияткә ия булуы «Ак мәчет» мисалында раслана.

***Төп төшенчәләр:*** мәктәп, реформа, Алтын Урда, мәгариф, Карл Фукс, мәдрәсә, конференция, нәтиҗә.

Татар мәктәбен мин шулай күз алдына китерәм: анда бөтен фәннәр дә татарча укытыла, фәкать дәүләт теле буларак урыс теле кирә һәм планда каралганча бер чит тел укытыла. Ул мәктәптә тәрбия эше дә татар милли традицияләренә нигезләнеп алып барыла. Минем белүемчә, Татарстанда, гомумән алганда Россиядә, андый мәктәп юк. Димәк, реформалаштыру объекты да юк. Татар мәктәбен реформалаштырырга түгел, бәлки иң элек формалаштырырга, ягъни оештырырга кирәктер.

Татар мәктәпләрен оештыру турында сүз алып барганда иң элек тарихыбызны исебезгә төшереп китсәк урынлы булыр: без кем идек һәм кем булдык?

«XIII гасыр башыннан башлап Бөек Новгородтан көньяк-көнчыгыш Азиягә кадәр, Дунай елгасыннан Япон диңгезенә кадәр иксез-чиксез даланы искиткеч, бөек, куәтле, беркайчан да таркал-

мас, мәңге яшәр кебек тоелган Жучи олысы, ягъни Алтын Урда дәүләте биләп тора» [1]. Алтын Урда Үзбәк хан идарә иткән елларда дәүләтләрнең иң көчлесенә әверелә һәм хәрби куәте, сәяси авторитеты белән үзенең иң югары ноктасына күтәрелә. Ул бөтен өлкәдә шундый кискен күтәрелеш кичерә. Бу Алтын Урданың рухи һәм матди өлкәләрне үз эченә алган үз мәдәниятенең, ягъни үзенә генә хас Алтын Урда мәдәниятенең тууы, үсүе турында сүз алып барырга мөмкинлек бирә. Әмма Алтын Урданың алтын чоры уза, ул аерым ханлыкларга таркала, ахырда ул ханлыклар да берсе артыннан берсе урыс дәүләте тарафыннан буйсындырылып үзләренең дәүләтчелекләрен югалталар. Шулай булуга карамастан, татарлар ассимиляцияләшмиләр, горур татар булып кала алалар.

Карл Фукс үзенең хатирәләрендә түбәндәгеләрне язып калдыра: «Казан татарлары 300 ел буйсынып яшәп тә шул кадәр күп үзенчәлекләрен һәм миллилекләрен саклап кала алганнар, бу хәтта күзәтүчән этнограф өчен дә аеруча игътибарга лаек. Алар урыслардан һәм башка халыклардан аерым яшиләр, хәтта хәзер дә үзләренең ата-бабадан калган өстенлекләрен, дәрәҗәләрен саклап калырга тырышалар. Алар үзләренең килеп чыгышлары белән, үзләренең әхлакый сыйфатлары белән, үзләренең диннәре белән, үзләренең яшәү рәвешләре белән, үзләренә генә хас бөтен сыйфатлары белән горурланалар» [2]. Алда әйтелгәннәр безнең кем булганыбызны күрсәтә.

Без – меңәр еллык мәгърифәткә ия булган бай тарихлы, борынгы халык. Безнең тарихыбызда зур күтәрелешләргә ирешкән һәм бик түбәнчелекләргә төшкән чорларыбыз да аз булмаган.

Карл Фукстан соң тагын 200 ел узды. Без тарихыбызны оныттык, затлы нәселдән икәнлегебезне оныттык, динебез зәгыйфьләнде. Кайчандыр бездән куркып, безгә карап сокланып торган дөнья бүген безнең кем икәнлегебезне дә белми. Бүгенге көндә бер татар мәктәбенең дә булмавы, балаларның татарча сөйләшә белмәве, халкыбызның үз милләте белән горурлану түгел, хәтта кимсенүе, безнең кем булганлыгыбызны күрсәтә. Шулай булса да, динебез, телебез, мәдәниятебез өчен көрәшәбез икән, димәк, киләчәгебез алай ук өметсез түгел.

Татар мәктәбен реформалаштыру проблемасы, минем фикеремчә, бу – милләтнең киләчәге өчен иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе.

Проблема дөрес күтәрелә: татар мәктәбе дип атала торган мәктәпләргә реформа кирәк, ягъни татар мәктәбе дип язу эленгән мәктәпләрдән чын мәгънәсендә татар мәктәбе ясарга кирәк. Әмма ничек ясарга? Моның өчен киләчәкне күз алдында тотып, киләчәккә карап эш йөртергә, үткәннәрдән сабак алырга кирәк.

Милләт мәсьәләсе Казан ханлыгы алынганнан бирле халык күңелендә ачы төер кебек тора. Ул үткәнен сагынып, киләчәккә зур өметләр белән яши.

Моннан 200 ел элек Курсави алып килгән дини реформа дини мәгарифнең реформалашуына, җәдитчелек хәрәкәтенә нигез салды, күп санлы мәгърифәтчеләр үсеп чыгуга сәбәп булды. Шул чордагы Европаның техник, технологик яктан алга китүе күпләрнең акылын томалады, киләчәкне күпләр Европа мисалында күрделәр. Күпләр өчен Европаның техник-технологик яктан алга китүе генә түгел, мәдәнияте, әхлагы, хәтта киенү рәвеше дә үрнәк иде. Үзебезнең меңәр еллык кыйммәтләребез юкка чыгарылды, аяк астына салып тапталынды. Алар өчен урыс теле, мәдәнияте шушы Европа мисалындагы якты киләчәккә алып бара торган бер күпер иде. Бик күп мәгърифәтчеләребез: «Урыс телен өйрәнмәсәк бетәбез!» – дип лаф орды. Гаяз Исхакый үзенең «200 елдан соң инкыйраз» дигән әсәрендә татар халкының 200 елдан бетәчәген һәм бетү сәбәпләренең берсе булып урыс телен белмәүне күрсәтте. Мин урыс телен өйрәнмәскә кирәк димим, әмма бүген үз ана телен белмичә, урыс телен генә белүе татар халкының бетүенә китерә торган иң зур сәбәпләрнең берсе икәнлеге ачык күренә. Бөек киләчәк вәгъдә итеп 200 ел элек башланган реформа татар халкын бик аяныч нәтиҗәләргә китерде. Бу ялгышу тагын да кабатланмаса иде.

Татар мәктәбе – ул милләтнең киләчәге. Татар мәктәбе турында сүз алып барабыз икән, без татар халкының киләчәген күз алдында тотып эш йөртергә тиешбез. Телибезме, теләмибезне беренче урында дини фактор, дини тәрбия булырга тиеш. Без Ислам динендә халык буларак формалашканбыз, безнең Ислам динендә 1000 елдан артык тарихыбыз бар. Урыслар бит үзләренең бөтен эшләрен диннәренә таянып кына алып баралар, аларның бөтен уку-укыту системасы христианлаштыруга корылган. Бүгенге мәктәп дәреслекләрен генә алып карагыз. Алар халыкны христианлаштыру белән сугарылганнар. Мәсәлән, «Окружающий мир» дигән дәреслек. Анда хәтта бизәкләргә кадәр урыс-христиан күзлегеннән карап аңлатыла-

лар һәм мисал итеп тә фәкать урыс-христиан бизәкләре, рәсемнәре генә китерелә. Урыс балалары өчен бу бик дөрес, әмма татар балалары өчен түгел. Бүген башкаларга ярыйбыз дип, татар халкы киләчәктә юкка чыккан халыклар исемлегенә кермәсә иде.

90 нчы елларда дин ирегеге кертелде. Россия төрле илләрдән кергән Ислам динен таратучы миссионерлар белән тулды. 70 ел динсезлектә гомер кичергән, үзенең диненә сусаган халык өчен аларның һәрберсе пәйгамбәр булып күренде. Без аның уңышын бүген җыябыз: элек мөселманга, атеистка гына бүленгән булсак, бүген мөселманнар үзләре генә дә бихисап төркемнәргә бүленде. Коммунистик идеологиягә бирешмәгән барлы-юклы гореф-гадәтләребез дә бетәр дәрәҗәгә җитте. Без: «1000 еллык ислам тарихыбыз бар», – дип әйтәбез икән, ул безнең татарның ислам тарихы, ә каяндыр кайтарылган түгел.

Безгә шуны дөрес аңларга кирәк: без Европа халкы да түгел, гарәп тә, фарсы да түгел, ә кайчандыр дөнья белән идарә иткән бөек мөселман татар халкы, Карл Фукс күреп гаҗәпләнгән, үзенең дине, дәрәҗәсе, яшәү рәвеше белән горурлана торган горур, баш имәс татар халкы. Шуңа күрә безнең үз мәгарифебез, үз мәдәниятебез-тәрбиябез белән сугарылган үз татар мәктәбебез булырга тиеш. Ни өчен безгә, кайчандыр үзебезнеке булган, хәзер исә Европага чыгып бозылган, Европага яраклаштырылган уку-укыту системасын күчерергә, нигә үзебезнең асыл системабызны өйрәнеп, үзебезнең югалган кыйммәтләребезне торгызмаска? Без әле һаман да үзебезгә тиешле бәя бирә белмибез. Әлбәттә, Карл Фукс татарлар турында бик күп яхшы сүзләр әйтеп калдыра, әмма аны иң гаҗәпләндергәне татарларның белемле булулары. Ул әйтә: «Читтән килгән кешегә Казан татарларының европалыларга караганда белемлерәк халык булуы, һичшиксез, гаҗәп тоела. Укый-яза белмәгән татар кешесен милләттәшләре, гомумән, хөрмәт итми» [3, б. 25].

Безгә үзенең бөтен кыйммәтләрен көчләп тага торган Европа бер җенестәш никахларга кереп батып юкка чыгып бара. Ә беренче карашка анда бар да үрнәк. Әмма анда гаилә төшенчәсе юк, әхлак юк, безнең халкыбызда тыелганнар анда гадәти хәл. Аңа ияру – ул милләтнең муенына элмәк элү. Европа дигәндә, «алар безгә иң яхшыларын тәкъдим итәләр», дип уйларга кирәк түгел. Алар үзләрендә түбән катлам өчен булган, яисә кулланышта булмаган һәм бүгенге көндә гамәлдән чыгарылганнарын тәкъдим итәләр. Ә

бит аларның бүгенге көндә иң дәрәҗәле, без мөкиббән китә торган уку йортларындагы эш процессы асылда үзе үк мәдрәсәләр үрнәгендә оештырылган. Атаклы совет галиме Сергей Петрович Капица әйткән: «Чынлыкта, югары дәрәҗәдәге белемгә остазлар белән даими ныклы мөнәсәбәттә булу белән генә ирешеп була. Бу яктан караганда Кембридж һәм Оксфордның мәдрәсәләр белән уртаклыклары бик күп. Барыгыз Бохарага, Сәмәркандка – анда мохит нәкъ шулай оештырылган: шәкертләр остазлар белән бергә яшиләр һәм остазлар шәкертләрнең тәрбиясе белән шәхсән һәм даими рәвештә шөгыльләнәләр. Бергә яшәүләре сәбәпле алар беркая да китә алмыйлар. Монда шулай ук шәкертнең актив эшчәнлек алып бара торган коллективка иртә кереп китүе дә зур әһәмияткә ия» [4].

Шунысы мөһим: безнең үз татар мәктәпләребез бар бит. Алар, күпләр игътибар итми торган, хәтта кимсетеп карый торган безнең мәдрәсәләребез. Әлбәттә, алар дәүләт уку йортлары, мәктәпләре белән чагыштырганда бик аз һәм анда килгән укучыларны да иң яхшы сыйфатлылары дип әйтеп булмас иде. Әмма мәдрәсәдә уку дәверендә алар танымаслык булып үзгәрәләр. Мәдрәсәдә укып белем алган, мәдрәсәне тәмамлаган шәкертләр бүгенге яшьләргә үрнәк булып торалар. Мәдрәсә дигәндә мин Татарстанда эшләп килә торган барлык мәдрәсәләрне дә күз алдында тотып әйтәм һәм, аерым алганда, Яр Чаллы шәһәре «Ак мәчет» мәдрәсәсе моның ачык мисалы булып тора.

«Ак мәчет»тә эш традицион динебезгә, милли гореф-гадәтләребезгә таянып, замана таләпләренә туры килә торган итеп, фәнни-тикшеренү эшчәнлеге белән бердәм процесс буларак алып барыла. Тәрбияви чаралар мәдрәсә эшенең аерылгысыз өлеше булып торалар.

«Ак мәчет» – мәчет-мәдрәсә һәм мәхәллә булып эшен алып бара торган бер комплекс ул. Мәдрәсә буларак аның көндезге, кичке һәм читтән торып уку бүлекләрендә бүгенге көндә 270 студент белем алса, 2017–2018 уку елында 1355 кеше 87 төркемдә мәчет каршында оештырылган якшәмбе мәктәпләренә йөреп башлангыч дини белем үзләштерде, ислам тәрбиясе алды. Без мәчеттә һәм мәдрәсәдә бик күп тәрбияви чаралар үткәрәбез. Мәдрәсәнең көндезге бүлегендә укучы шәкертләребез бу чараларны күреп, үзләре үк шул чараларда катнашып зур тәрбия мәктәбен үтәләр.

Мәдрәсәбездә фәнни-тишеренү эшчәнлегенә аеруча зур игътибар бирелә. Курс эшләре һәм чыгарылыш квалификация эшләре уку-укыту планының аерылгысыз өлеше булып тора. Бу эшләрне башкарып шәкертнең фәнгә, тарихыбызга, гореф-гадәтләребезгә мөнәсәбәте яхшыра, ихтирамы арта. Курс эшләрен һәм чыгарылыш квалификация эшләрен яклау процессында сөйләм осталыгы камилләшә.

Без бер республикакүләм һәм бер россиякүләм, дүрт халыкара конференция, бер халыкара семинар уздырдык һәм бездә конфренцияләр оештыру-уздыру инде традициягә әйләнде. Бу чараларда Россиянең төрле шәһәрләреннән һәм чит илләрдән дин һәм фән галимнәре бик теләп катнаштылар. Без эшчәнлегебезне Россия ислам институты, Яр Чаллы дәүләт педагогия университеты, Идел буе федераль университеты, Мәскәү дәүләт лингвистика университеты кебек уку йортлары, Тарих институты, Татарстан фәннәр академиясе кебек мәртәбәле фән үзәкләре, анда эшләүче мәшһүр галимнәр белән бергәлектә алып барабыз. Мәсәлән, 2018нче елның 17нче мартында узган «Җәмгыять тормышын тотрыкландыруда Ислам диненең әһәмияте» исемле чираттагы III Халыкара фәнни-гамәли конференция эшендә дөньяның 5 иленнән, Россиянең 6 шәһәреннән 14 профессор, фән докторлары, 28 фәннәр кандидаты, күренекле дин галимнәре катнашты. Монда милләткә, динебезгә, дини мәгарифкә багышланган бай эчтәлекле чыгышлар күп булды. Ә иң әһәмиятлесе шул: 5 секциянең 2се мәдрәсә шәкертләре, дини һәм дөньяви югары уку йортлары студентлары өчен махсус оештырылган иде.

2016нчы елның 17нче декабрендә мәдрәсәбездә XVIII гасыр ахыры – XX гасыр башында Татарстанның көнчыгыш төбәгендә эшләгән мәдрәсәләр һәм шул чорда укыткан укытучыларга багышланган «Татар ислам мәгарифе тарихы» дип аталган музей ачылды. Бу музейның ачылуы шулай ук яшь буынны тәрбияләүдә зур роль уйный.

14 нче май көнне «Ак мәчет»тә «Тел, әдәбият һәм мәдәният бәйләнышлары» дигән халыкара тюркологик семинар булды. Бу семинар эшендә Яр Чаллы «Ак мәчет» мәдрәсәсе, Яр Чаллы дәүләт педагогия университеты, Казан (Идел буе) федераль университетының Яр Чаллы институты, Казахстан республикасы Жубанов исемендәге Актүбә региональ дәүләт университеты галимнәре катнашты.

Бу елның 20нче октябрендә узган Әхмәдһади Максудиның 150 еллыгына багышланган «XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар мөселман мәгарифе» дип аталган халыкара фәнни-гамәли конференция эшендә 12 фән докторы, 12 фән кандидаты, дин галимнәре катнашты. Әлеге конференциябез дә искиткеч бай эчтәлекле булды.

Без конференцияләр уздырып кына калмыйбыз, бәлки конференция материалларыннан зур күләмле җыентыклар да бастырабыз. 2017нче елда уздырылган халыкара конференция материалларыннан эшләнгән җыентык РИНЦка (Российский индекс научного цитирования), ягъни «Россия электрон китапханәсе»нә кертелде һәм бүген бу конференция материалларын бөтен дөньяда карый һәм куллана алалар. Эшләнгән эшләр кемгәдер гадәти сыман тоеладыр, әмма без бит гади бер татар мөселман мәдрәсәсе, шәкертләребезнең дә зур күпчелеге 9 класс тәмамлап килгән мәктәп укучылары гына һәм бу чараларны без бюджет акчасына да үткәрмибез.

Без бүгенге көндә Казахстан, Төркия уку йортлары белән аралашабыз, эш тәҗрибәләре белән уртаклашабыз, тарихи чыганаклар, әдәби һәм дини мирас мәсьәләләрендә бер-беребезгә ярдәм итәбез. Киләчәктә бу аралашуга башка илләрдәге уку йортлары да кушылыр дип өметләнеп калабыз.

Безнең эшчәнлек конференцияләр, семинарлар уздыру белән генә чикләнми. Мәдрәсәбездә даими рәвештә шәһәребезнең төрле югары уку йортларыннан дәрәҗәле фән галимнәре килеп төрле лекцияләр белән чыгыш ясасалар, мәдрәсәбез остазлары югары уку йортлары студентлары алдында динебез турында чыгыш ясыйлар. Бу традицион динебезне дәгъват кылу, милли гореф-гадәтләрне торгызуда бик үтемле чара булып тора.

Ә инде мәдрәсә эшчәнлегенә бәя булып мәдрәсәне тәмамлаучы шәкертләрнең мәдрәсәдән соңгы эшчәнлекләре, халык тарафыннан алар турында әйтелгән мактау сүзләре, рәхмәтләре тора.

Нәтиҗә ясау рәвешендә, түбәндәге төп юнәлешләрне билгеләргә мөмкин:

1. Татар мәктәбенең эшчәнлеген үзебезнең традицион ислам диненә һәм милли гореф-гадәтләребезгә нигезләнеп, шәкерт белән остаз бергә яши торган итеп, мәктәп-интернат рәвешендә оештыру.

2. Фәнни-тикшеренү эшчәнлеген уку-укыту процессының аерылгысыз, мәҗбүри үтәлергә тиешле бер өлеше булуын тәэмин итү.

3. Әлеге максатларны тормышка ашыруда мәдрәсәләр тарафыннан тупланган уңай эш тәҗрибәсенә игътибар итү һәм нәтиҗәле итеп куллану.

4. Алда әйтеп кителгән юнәлешләрнең үтәлешен тәэмин итү өчен кирәкле материаль-техник база булдыру һәм рухи мохит тудыру.

ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ЧЫГАНАКЛАР


1. Тюркский мир. № 21. Реформы Хана Узбека. [Электронный ресурс] Режим доступа: https://www.youtube.com/watch?v=2dcPDtYhsNQ

2. Карл Фукс о Казани и татарах. [Электронный ресурс] Режим доступа: https://ok.ru/vsetatarynaodnolitco/topic/67200364882737

3. Сәхипова Р.Ә. Халык педагогикасы нигезендә укыту һәм тәрбия бирү. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 256 б.

4. О подготовке высококвалифицированных кадров профессионалов по С.П. Капице. [Электронный ресурс] Режим доступа: https://vikent.ru/enc/3697/


## СОВРЕМЕННЫЕ ПРОБЛЕМЫ НАЦИОНАЛЬНОГО ВОСПИТАНИЯ И МУСУЛЬМАНСКОГО ОБРАЗОВАНИЯ ДЕТЕЙ И ОПЫТ МЕДРЕСЕ «АК МЕЧЕТЬ» В ИХ РЕШЕНИИ


***Шайхвалиев Рустам Шайхразиевич,***
*Медресе «Ак мечеть», г. Набережные Челны,*
*imam@akmechet.ru*



В статье речь идет о необходимости реформирования татарской школы. Автор обосновывает, что реформа должна касаться как учебного, так и воспитательного процесса. Здесь дается анализ истории татарского народа, его просвещения и аргументируется необходимость нового подхода к образованию и воспитанию. По мнению автора, в реформировании школы большую роль играет научно-исследовательская работа, и это показывается на примере медресе «Ак мечеть».



***Ключевые слова:*** школа, реформа, Золотая Орда, просвещение, Карл Фукс, медресе, конференция.

# MODERN PROBLEMS OF NATIONAL UPBRINGING AND MUSLIM EDUCATION AND THE EXPERIENCE OF “WHITE MOSQUE” MADRASSA IN THEIR SOLUTION

***Shaykhvaliev Rustam,***
*“White Mosque” Madrassa, Naberezhnye Chelny,*
*imam@akmechet.ru*

The report deals with the need to reform of the Tatar schools. The author justifies that the reform should concern both the education and the moral upbringing. It gives an analysis of the history of the Tatar, their enlightenment and argues the need for a new approach to education and upbringing. According to the author, student’s research work plays an important role in school reform, and this is shown on the example of the “White Mosque” Islamic School.

***Keywords:*** school, reform, Golden Horde, enlightenment, Karl Fuchs, madrassa (Islamic School), conference.

УДК 78

# МУЗЫКАЛЬНОЕ ВОСПИТАНИЕ КАК ФАКТОР ФОРМИРОВАНИЯ ЦЕННОСТНЫХ ОРИЕНТАЦИЙ УЧАЩЕЙСЯ МОЛОДЕЖИ: НА ПРИМЕРЕ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

***Миннегулов Раис Мотигуллович,***
*кандидат социологических наук,*
*Набережночелнинский педагогический колледж,*
*г. Набережные Челны*
*ra4xom22@bk.ru;*

***Портнова Алсу Монировна,***
*учительница Набережночелнинской школы № 3,*
*г. Набережные Челны*

Статья посвящена освещению роли музыкального воспитания в формировании ценностных ориентаций учащейся молодежи. Авторы показывают важное значение музыкального наследия, фольклора, культурных традиций в духовно-нравственном развитии подрастающего поколения.

***Ключевые слова:*** татарская музыка, мелодия, композитор, музыкальное образование.

В современных условиях в Российской системе образования актуальным направлением является формирование культурообразующей компетенции учащейся молодежи, для которой сохранение и развитие культурных традиций начинается со своего региона, города. Особая роль в этом отводится семье, которая является хранителем и создателем культурных традиций и организатором совместной досуговой деятельности в потреблении этно-музыкальных ценностей. Процесс формирования духовно-нравственных ценностей в сознании ребенка и приобщение его к истокам национального музыкального языка начинается с колыбельных песен матери (бишек җыры, «моң»). Получая в семье первые музыкальные впечатления, ребенок привыкает к родному языку, мелодиям национальной музыки, постигает интонационный словарь своего народа. Музыкальный язык – неотъемлемая и важнейшая часть любой

национальной культуры, полноценное знакомство с которой начинается с проникновения в специфику выразительных средств музыки. Музыка национальна – начиная от джаза, родившаяся из сплава различных фольклорных течений американского континента – танцевальной, песенно-бытовой и ритуальной музыки американских негров, до простых мелодий русских былинных песен, татарских мунаджатов. Слово «мелодия» происходит от древнегреческого – «мелос», что означает «песня». Мелодический язык музыки обладает неисчерпаемо богатыми возможностями. В произведениях композиторов-классиков народ получает свой «голос».

Великие музыканты глубоко осознавали значение для творчества композитора национального фольклора и национальных традиций: «Музыки вне национальности не существует, – писал русский композитор Римский Корсаков, – и, в сущности, всякая музыка, которую принято считать за общечеловеческую, все-таки национальная» [1, с. 217].

Формирование творческих принципов основоположника татарской профессиональной вокальной и инструментальной музыки С.Сайдашева также началось с изучения татарских народных песен. На это его вдохновили слова любимого поэта Г.Тукая (многие стихи которого он знал наизусть): «Настоящий народный язык и истинный дух народа мы можем найти только в народных песнях» [2, с. 19]. С.Сайдашев, как и Г.Тукай в поэзии, был воодушевлен идеей создания татарской профессиональной музыки. Раньше среди татар существовало только устное народное музыкальное творчество. Музыкальное образование для простого народа было практически недоступно, не было и профессиональных композиторов. Бытовали одноголосные песни, основанные на пентатонике и «мунаджаты, «баиты» – старинные песнопения философского или религиозного содержания.

Некоторые представители татарской диаспоры неодобрительно относились к профессионализации татарской музыки, считали необходимым сохранение одноголосия и пентатоники и с этих позиций критиковали С.Сайдашева. Так, в рецензии на музыкальную драму «Зәңгәр шәл» его музыку характеризуют как «недоваренную русско-татарскую кашу» [3, с. 13]. В принципиальных вопросах развития татарской музыки С.Сайдашев был твердо убежден в верности избранного пути. По этому поводу он написал статью «Един-

ство мелодий», в которой доказывал, что татарское музыкальное искусство может развиваться только при условии взаимообогащения музыкальным искусством русских и зарубежных композиторов. Музыка С.Сайдашева отличается многообразием форм и жанров, является глубоко лиричным по своей природе. Примерно за одно десятилетие, в 1922–1932 гг., Сайдашев написал музыку к более 30 спектаклям. Наиболее значимые из них – это музыкальные драмы «Зәңгәр шәл», «Наемщик», «Кандыр буе». Детские песни С.Сайдашева – дар большого художника детям. Мир детей и юношества, запечатленный в музыкальных образах – одна из важнейших граней творческого дарования выдающегося композитора.

Президент страны В.В.Путин, выступая перед участниками молодежного форума в Ставропольском крае 15 августа 2018 года, высказался о необходимости сохранения национальных языков на современной основе. Это выступление дало дополнительный импульс в преподавании татарского языка и в преподавании языка народов, проживающих в Республике Татарстан.

Музыка и поэзия имеют множество точек соприкосновения. Недаром эти два искусства так часто и естественно сочетаются, порождая важнейшие жанры: песню и романс. Музыка и речь особого рода, тесно связаны с обыкновенной словесной речью. И, наоборот, можно сказать, что наша речь есть своего рода мелодия, например: мы слышим в ней повышение тона и понижение, ускорение или замедление.

С целью сохранения и возрождения национального музыкального наследия и формирования ценностных ориентаций учащихся, нами совместно с Институтом филологии и межкультурной коммуникации Казанского (Приволжского) федерального университета была разработана и составлена «Хрестоматия» по музыке для I–IV классов татарских школ. В данный сборник включены более 120 песен классиков татарской музыки, таких как С. Сайдашев, Ф. Яруллин, Дж. Файзи, А. Бакиров, песни современных композиторов и народные песни. Сейчас этим сборником пользуются в детских дошкольных учреждениях, в учреждениях дополнительного образования и общеобразовательных учреждениях Республики Татарстан. В виду того что учреждения дополнительного образования не могут охватывать всех учащихся, важным звеном музыкального образования являются общеобразовательные учреждения. Только в

общеобразовательных учреждениях может быть организовано музыкальное образование всех учащихся без исключения, на основе единых принципов и учебных программ.

Мы внимательно изучили учебники музыки с I по VIII классы и развернутое поурочное тематическое планирование по предмету «Музыка» под редакцией Е.Д.Критской, по которым учатся все общеобразовательные учреждения республики. А также изучили программу для татарских школ и гимназий с I по VIII классы, выпущенную издательством «Магариф» в 1997 г., и программу под редакцией Р.Т.Сайфуллиной «Музыка дәресләре» для V–VII классов татарских школ, выпущенную издательством «Магариф» в 2004 году. Следует отметить, что в содержании рабочих программ и учебно-методических комплексов по дисциплине «Музыка» под редакцией Е.Д.Критской и в программе «Музыка дәресләре» под редакцией Р.Т.Сайфуллиной нет нотного приложения народных песен и песен классиков татарской музыки.

Не случайно, школьные уроки музыки в советское время называли именно уроками пения потому, что именно песня многообразно отражает жизнь человека, раскрывает духовные качества и богатство его дум и чаяний. И именно в песнях отражается национальная идентичность и извечные стремления человека к добру, честности. В детском хороводе-игре «Кария-Закария» один ученик остается в кругу, а остальные водят хоровод вокруг него. Подбираются слова, подчеркивающие способности участника и возвышающие его индивидуальность, например: что он хороший ученик, хороший музыкант или танцор, хороший друг и т.д. В этом хороводе – игре взаимодействуют все основные элементы художественного творчества: словесные, музыкальные. Если пение с инструментальным сопровождением способствует развитию вокальных навыков участников, то танцевальные элементы хоровода помогают совершенствовать хореографическую подготовку, а мимика и жесты развивают артистизм.

Как известно, и венгерский педагог Золтан Кодай придавал большое значение пению простых народных песен, построенных на пентатонике и использованию движений для улучшения качества исполнения музыки. Движения могут соответствовать содержанию песни или же отражать сильную и слабую долю. В старших классах внешнее движение переходит во внутреннее переживание ритма и

пульса музыки. Золтан Кодай считает, что «обучение нотной грамоте так же необходимо для понимания музыки, как чтение словесного текста на уроках литературы. Кто не умеет читать ноты, музыкально безграмотен» [4, с. 275].

Среди причин и недостатков в сфере музыкального образования нас волнует:

- отсутствие концепции перспективного развития системы музыкального воспитания и музыкального образования на федеральном и республиканском уровнях;
- пренебрежение внедрением национально-регионального компонента в музыкальном образовании;
- падение престижа музыкального образования, вследствие этого низменные потребности учащейся молодежи в музыкальном искусстве;
- повальное увлечение молодежи развлекательной музыкой, где в центре внимания оказывается разные приключения, бездумное веселье.

Популярность и доминирование в современной социокультурной среде музыки развлекательного характера (танцевальной, солонной, рекламной, поп музыки), на наш взгляд, объясняется близостью эмоционального вознаграждения (для этого не обязательно изучать нотную грамоту, научиться играть на музыкальных инструментах, не обязательно знать содержание музыкально-художественных произведений). Развлекательная музыка типа «Зайка моя» сама по себе бессодержательна, рассчитана на обывателей, быстро приедается и быстро забывается. Самое главное то, что воспитывается новое поколение молодежи, которая все дальше отдаляется от национальных корней музыки и от классического музыкального искусства.

Безусловно, представленный подход к формированию ценностных ориентаций учащейся молодежи посредством музыкального воспитания – это лишь определенный аспект проблемы. Но, тем не менее, мы считаем, что данный подход способен обеспечить положительные результаты в духовно-нравственном развитии учащейся молодежи.

ЛИТЕРАТУРА

1. Римский-Корсаков Н. Летопись моей музыкальной жизни. – М., 1955. – 398 с.
2. Тукай Г. Избранное в 2-х томах. Т. 2. – Казань: Таткнигоиздат, 1961. – 514 с.
3. Садрижиганов Дж. Воспоминания. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. – 151 с.
4. Золтан Кодай. Избранные статьи. – М., 1982. – 288 с.

## MUSICAL EDUCATION AS A FACTOR IN THE FORMATION OF VALUE ORIENTATIONS OF STUDENTS: ON THE EXAMPLE OF THE REPUBLIC OF TATARSTAN

***Minnegulov Rais,***
*Candidate of Sociological sciences,*
*Naberezhnye Chelny pedagogical College, Naberezhnye Chelny*
*ra4xom22@bk.ru;*

***Portnova Alsu,***
*teacher of Naberezhnye Chelny School No. 3,*
*Naberezhnye Chelny*

The article dedicated to the role of musical education in the formation of value orientations of students. Authors show the importance of musical heritage, folklore, cultural traditions in the spiritual and moral development of the younger generation.

***Keywords:*** Tatar music, melody, composer, musical education.

УДК 81.373

# ТӨБӘК ТАРИХЫН ӨЙРӘНГӘНДӘ ТОПОНИМИК МАТЕРИАЛЛАРДАН ФАЙДАЛАНУ

***Хаҗиев Ринал Исмәгыйль улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Яр Чаллы дәүләт педагогия университеты, Яр Чаллы,*
*haziev.rinal@mail.ru*

Мәкалә төбәк тарихын өйрәнүдә иң мөһим чараларның берсе булган топонимик материалларны файдалану мәсьәләсенә багышлана. Автор укучыларның фәнни эшләренең төп төрләрен тәкъдим итә.

***Төп төшенчәләр:*** тарих, топонимика, урынчылык, өйрәнү, фәнни хезмәт.

Тел гыйлеменең топонимика тармагы телебездәге барлык төр географик атамаларны (җир-су атамаларын) җыйнау-барлау, тикшерү эше белән шөгыльләнә.

Топонимик материалларны төбәк тарихын өйрәнгәндә куллану мөмкинлеге хакында күп галимнәр тарафыннан искәртелә килә. Мәсәлән, Казан төрки-татар ономастика мәктәбен нигезләүче галим, профессор Гомәр Фәез улы Саттаровның «Татар топонимиясе» (Казан, 1998) хезмәтендә мондый юллар бар: «Ономастика мәгълүматлары (башлыча топонимика һәм микротопонимика, антропонимика, этнотопонимика, ойконимика һ.б. мәгълүматлары) тел тарихы, тарихи лексикология, диалектология, халык тарихы, топо- һәм этногенез, этнография, крайны өйрәнү, археология, философия, этика һәм эстетика, геология, география, биология һ.б. кебек фәннәр өчен кыйммәтле чыганак булып торалар, бу фәннәрне тагын да үстерүдә үзләреннән шактый зур өлеш кертәләр» [1, б. 4].

Бу турыда күренекле галимә, профессор Фирдәүс Гарифҗан кызы Гарипованың фикере дә кызыклы. Ул «Рухи башкалабыз: Мәшһүр татар авыллары» (Казан, 2005) хезмәтендә болай дип яза: «Миңа, хезмәтемә бәйле рәвештә, озак еллар Татарстан районнарында һәм аннан читтәге татар авылларында экспедиция-сәфәрләрдә йөрергә туры килде. Йөзләгән авылларның ямен үз күзләрем белән күрдем, чишмәләреннәнятып су эчтем, хәтфәдәй чирәмнәренә утырып ял иттем, нурлы йөзле әби-бабайлары, гади, эчкер-

сез халкы белән аралаштым, аларның нәсел-нәсәпләре, мәктәп һәм мәчетләр тарихы, географик атамалар, фольклор дөньясына нисбәтле мәгълүматлар белән таныштым һәм халык хәтеренә таң калдым!» [2, б. 3].

Димәк, тарихи-топонимик тикшеренүләрнең әһәмияте бәхәссез.

Соңгы елларда халыкта үзләре яшәгән төбәк тарихы белән кызыксыну артканнан-арта бара. Бу аңлашыла да, чөнки халыкның үз тарихи тамырларын яхшырак беләсе килә.

Топонимика тармагы үзенең кызыклы-мавыктыргыч булуы белән укучыларны һәм студентларны да җәлеп итә. Шул сәбәпле, күп кенә укучылар реферат өчен, студентлар исә курс һәм чыгарылыш квалификация эшләре өчен тема сайлаган вакытта еш кына ономастиканың топонимика тармагына мөрәҗәгать итәләр.

Гомумән, төрле характердагы фәнни хезмәтләр башкарганда төп эш юнәлешләрен дөрес итеп билгеләү зарур. Без биредә төбәк тарихына һәм топонимиясенә караган түбәндәге эш юнәлешләрен тәкъдим итә алабыз:

1. Хезмәт өчен тема сайлау.
2. Фәнни эшнең эчтәлеген (содержание) төзү.
3. Консультацияләр графигын булдыру.
4. Хезмәтне язу барышында материаллар туплау.
5. Фәнни эшне техник яктан дөрес оештыру.
6. Хезмәтне бастыру.

Укучылар өчен бирелгән темалар артык киң яки артык катлаулы булырга тиеш түгел. Мәсәлән, мондый формада була ала:

1) «Иске Айман төбәгенә караган топонимнар»;
2) «Авылым чишмәләре»;
3) «Азнакай шәһәрендәге урам исемнәре» һ.б.

Югары уку йортлары студентлары өчен тәкъдим ителгән темалар да төрле характерда һәм эчтәлектә булырга мөмкин. Башкача әйткәндә, тема топонимиканың төрле тармакларын колачлый ала: оронимика, ойконимика һәм гидронимиканы.

